Шаһит язмалары

Бәкердә, Кәшшаф мулланың нигезе, ул салдырган таш келәтләр бүген дә тора әле... Тарих шактый зур, шуңа күрә, бүгенге язмада аның кайбер өзекләренә генә тукталаса иттем. Әйтик, Кәшшафетдин үзе шаһит булган 1921 елгы ачлык галәмәтләренә, мәчетләр салыну тарихына, кайбер муллалар турындагы кызыклы мәгълүматка. Бүген тарих белән кызыксынучылар байтак. Бәлки әлеге язма кемнәргәдер кызыклы тоелыр. Тере истәлек ич бу.

10 БИТ

Чулпан Йосыпова:

«Мин вакытны куалыйм»

«Үз алдыма максат куйсам, шуны ахырга кадәр җиткермичә туктамыйм. Бу сыйфат әтиемнән күчкән. Аннан соң холкымда андагы «егетлек» сыйфатлары да чагыла. Кечкенә чакларда аның белән бергә ауга, балык тотарга йөри идем.»

7 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Җомга | 17.02.2017 | № 17 (5779)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

АЛДАМЫЙЛАР

Былтыргы тикшерүләр буенча, Татарстанда 51,1 мең кап сыйфатсыз дару әйләнештән алынган, 43,2 мең төргәк медицина эшләнмәсе яраксыз дип табылган. Саннар шомландырса да, ялган дарулар фармацевтика өлкәсендәге барлык препаратларның 1 процентын гына тәшкил итә икән.

Эльвира МОЗАФФАР

– Халык арасында «даруларның хәтта 60 проценты ялган» дигән имеш-мимешләр йөрсә дә, чынлыкта фальсификация аз очрый, – диде «Татар информ»да узган матбугат конференциясендә Татарстанның Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте идарәсе җитәкчесе урынбасары Любовь Шәйхетдинова.

Былтыр әлеге хезмәт идарәсенә барлыгы 1003 мөрәҗәгать кабул ителгән. Бу, узган ел белән чагыштырганда, өч тапкырга диярлек күбрәк. (2015 елда 672 шикаять кабул ителгән булган.) Халыкны күбесенчә сыйфатсыз медицина ярдәме күрсәтүгә кагылышлы сораулар, дарулар белән тиешенчә тәэмин ителмәү проблемасы борчый. Ялган даруларга караганда, фармацевтика өлкәсендә «брак» дип танылган дарулар күбрәк очрый икән. Еш кына кабындагы хәреф дөрес язылмаганга, дару төймәсенең эрү үзенчәлеге тиешле нормаларга җавап бирмәгәнгә һәм башка сәбәпләр аркасында, алар яраксыз булып санала.

– Ничек кенә булмасын, медицина препаратларының барысы да даруханә челтәрләренә килеп җиткәнче тикшерү уза, һәм сыйфатсызлары кулланылыштан алына, – дип ышандыра Татарстанның Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте идарәсе җитәкчесе Рөстәм Сафиуллин.

Соңгы вакытларда «махсус акция кысаларында сәламәтлегегезне тикшерәбез, тулы диагностика курсы уздырабыз» дигән ялган клиникалардан зыян күрүчеләр артып киткән. Әйтик, Татарстанда бер хатынга дәвалый торган ортопедик юрган, матрас, мендәр тышларын 130 меңгә сатканнар. Нәтиҗәдә бу гап-гади урын-җире әйберләре булып чыккан. Мондый очракларда дөреслекне раславы авыр. Шуңа да белгечләр халыкка кредит рәсмиләштерергә үгетләгән, үз продукциясен алырга кушкан клиникалар белән сак булырга киңәш итә.

Рөстәм САФИУЛЛИН, Татарстанның Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте идарәсе җитәкчесе:

– Былтыр барлыгы 286 тикшерү уздырдык. Алар арасында планлы, лицензия алыр алдыннан үткәрелә торган, шулай ук халыктан килгән шикаятьләр буенча плансыз тикшерүләр дә бар. Нәтиҗәдә, 182 беркетмә төзелеп, эшләр судка тапшырылды. 159 очракта кисәтү ясалды. Барлыгы 3 миллион 676 сумлык штраф салынды.

tatarstan.ru

СЕЗ ДӨНЬЯНЫҢ ИҢ МАТУР БАШКАЛАЛАРЫНЫҢ БЕРСЕН ТӘКЪДИМ ИТӘСЕЗ, ПАРИЖ ПАРИЖ ИНДЕ. ПАРИЖДАН СОҢ БЕЗ, ӘЛБӘТТӘ

Рөстәм Миңнехановның Париж мэры Анн Идальгога әйткән сүзе.

Казан белән Париж Европага «тәрәзә» ача

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм Казан мэры Илсур Метшин 16 февральдә Кремльдә дуслык визиты белән килгән Париж мэры Анн Идальго җитәкчелегендәге француз делегациясен кабул иттеләр.

Вакыт табып Казанга килгәне, гомумән, республика белән кызыксынганы өчен, Рөстәм Миңнеханов Анн Идальгога рәхмәт белдерде.

– Россия – Франция мөнәсәбәтләре кысаларында, төбәкара дәрәҗәдәге хезмәттәшлекне югары бәялибез, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Анн Идальгоның «Берләшкән шәһәрләр һәм җирле хакимият» Бөтендөнья оешмасы (ОГМВ) ассылыгындагы эшчәнлегенә дә югары бәя бирде.

– Җирле хакимият – һәр дәүләтнең нигезе, сез шушы нигезгә лаеклы хезмәт итәсез, – диде республика лидеры.

Президент искәрткәнчә, Татарстанда Франциянең берничә компаниясе эшчәнлек алып бара. Казан Кремле һәм Болгар музей-тыюлыгы ЮНЕСКО бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелгән. Зөя утрау-шәһәрчегендәге Успенский соборын да ЮНЕСКО исемлегенә кертергә әзерлек бара. Татарстан Президенты фикеренчә, милли бәйрәм – Сабан туе да ЮНЕСКОның матди булмаган мирасы исемлегенә кертелергә лаек.

– Париж белән Казан тарафыннан имзаланган хезмәттәшлек турындагы килешүне хуплап кабул иттек. Бу яхшы хәбәр, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Дәвамлы килешү уртак чаралар оештыруны, мәгълүмат алмашуны, туристлык, инвестиция хезмәттәшлеген, мәдәни проектларны күздә тота.

Рөстәм Миңнеханов белән Анн Идальго 2017 елда Парижда Сабан туе үткәрү мәсьәләсен дә ачыкладылар. Казан мэры Илсур Метшин Парижда Анн Идальго белән очрашу вакытында да бу хакта килешкәннәр иде. Парижда Сабан туен май ае ахырларында уздыру ниятләнелә.

Рөстәм Миңнеханов туристлык, спорт, мәгариф өлкәсендәге хезмәттәшлекне үстерүнең мөһимлеген дә искәртте.

Париж мэры Анн Идальго җавап сүзендә Татарстанның һәм Казанның халыкара дәрәҗәдәге спорт чараларын әзерләүдәге, үткәрүдәге, иминлекне тәэмин итүдәге тәҗрибәсе кызыксыну тудыруын билгеләп үтте. Парижның туристлык өлкәсендәге тәҗрибәсе белән уртаклашырга әзер булуын әйтте.

– Парижда халыкара Бальзак лицее бар. Мөгаен, алмаш буенча бер сыйныф монда килер, шулай ук сезнең балалар безгә килә алыр, – диде Анн Идальго.

Ул Казандагы «Альянс Франсез» француз теле һәм мәдәнияте үзәге өчен республика җитәкчелегенә рәхмәтен ирештерде.

– Казанда төрле мәдәниятләр, диннәр дус-тату яши. Парижда Ислам мәдәнияте үзәге эшли, – дип дәвам итте Анн Идальго, – Казанда төрле диннәрнең дус яшәве турында Парижның Ислам үзәгендә күргәзмә оештырып булыр иде.

Казан Ратушасында журналистлар белән очрашу булды.

– Казан мэры Илсур Метшин Парижда булды. Хәзер мин җавап визиты ясадым, үзем өчен гаҗәеп Казанны ачтым. Тәэсирләрем әйтеп бетергесез. Мэр Илсур Метшин җитәкчелегендә Казан гаҗәеп уңышларга ирешкән. Татарстан башкаласы яшь буынга йөз тотып төзелә. Биредә милләтләрнең, диннәрнең дус яшәве безнең өчен үрнәк. Хезмәттәшлек уңышлы барыр, без – оптимистлар, – диде Анн Идальго.

Мэр Илсур Метшин Париж мэры Анн Идальгоны, дөньяда иң чибәр хатын-кыз мэр, дип мактады.

– Хезмәттәшлек килешүенең нәтиҗәләре үзен озак көттермәс. Мондый аралашу шәһәрләр өчен кирәк, – диде Илсур Метшин.

Париж 2024 елда җәйге Олимпия уеннарын үзендә үткәрергә исәпли. Илсур Метшин: «Парижда Олимпия уеннарын Казанга алып кайтырбыз», – диде.

Казан мэры сер итеп әйткәнчә, Анн Идальго татар милли ризыкларыннан тавык шулпасын, өчпочмакны, гөбәдияне – һәркайсын ашап караган.

– Шулкадәр тәмле булды, унбиш көнлек тукландым. Казаннан искиткеч җылы тәэсирләр белән китәм, – диде Анн Идальго.

Дамир БӘДРИЕВ.

Башкалага эшлеклеләр җыелды

16-18 февральдә Казанда беренче мәртәбә «Winter Event Forum» үткәрелә. Россия күләмендә эшлекле туристлык темасына караган әһәмиятле вакыйга бу.

Шәһәр Башкарма комитетының туристлыкны үстерүгә теләктәшлек департаменты директоры Дарья Санникова әйткәнчә, форумда Россиянең 20 шәһәреннән 300 делегат катнаша. Моңа кадәр «Winter Event Forum» Мәскәү, Санкт-Петербург һәм Ростов-на-Дону шәһәрләрендә генә уздырылган.

– Кышкы «Event Forum» ул профессиональ оештыручыларның, менеджерларның, бизнес хуҗаларының, туристлык комитетлары вәкилләренең очрашу, хезмәттәшлек планнары кору мәйданы булуы белән мөһим, – диде Дарья Санникова.

Әлеге чараны «The Experience is Marketing» компаниясенә нигез салучы Кевин Джексон, режиссер, «Фабрика звезд» проекты продюсеры Лина Арифулина, «Подъежики» стратегик вакыйгалар агентлыгын оештыручы Михаил Воронин, «The Unthinkable» халыкара консалтинг агентлыгына нигез салучы Тимо Киру, «Event-маркетинг от А до Я» проектын төзүчеләр Наталья Франкель белән Дмитрий Румянцев та хуплаган.

Туристлык комитетлары вәкилләре өчен «Төбәкләрдә кышкы туристлыкны үстерү» темасына махсус ачык сессия оештырыла.

– Форумда Казанның колачлы спорт һәм мәдәни чараларны гына түгел, ә эшлекле юнәлеше программаларны да оештырырга сәләтле булуын танытуны максат итеп куйдык, – ди Дарья Санникова. – Форум кысаларында күргәзмә заллары, кунакханәләр, рестораннар белән танышу мөмкинлеге тудырыла, шәһәр буйлап экскурсияләр үткәрелә.

Мэр Илсур Метшин да вакыйгага нык әһәмият бирде.

– Эшлекле туристлык – мөһим юнәлеш. Бу хакта күп сөйләдек, инде сүздән эшкә күчү бик яхшы. Мондый зур чараның бездә үтүе үзе үк күп нәрсә турында сөйли. «Казан-Экспо», «Мәскәү-Казан» югары тизлекле тимер юл магистрале төзелгәч, һичшиксез, эшлекле тормыш та, чаралар да тагын да җанланачак. Бу үзгәрешләргә хәзердән үк җиңнәрне сызганып әзер булып тору кирәк, – диде Илсур Метшин.

Шәһәр башлыгы эшлекле чаралар оештыру өчен Казанның мөмкинлекләре күәтле булуын искәртте. Илсур Метшин: «Эшлекле туристлык безгә әлегә тулысынча колач җәеп тормый», – дип, бу юнәлешне максатчан үстерергә чакырды.

Рәдиф КАРАГАЙ.

«Үлемсез полк» – изге эш»

Дәүләт Советы депутаты ни өчен шелтә белдерде?

Дәүләт Советындагы кичәге сессия бүләк бирүдән башланды. Парламент рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты директоры Рафаэль Хәкимовка, 70 яшь тулу уңаеннан, «Парламентаризм үсешенә керткән өлеше өчен» Почет билгесе тапшырды.

gossov.tatarstan.ru

Линар ЗАКИРОВ

– Без бик озын юл үттек. Башта дәүләт суверенитеты турында декларация, аннары Татарстан Конституциясе, федераль үзәк белән ике килешү кабул ителде. Бүген мин сәяси тормыштан читләштем, аның каравы, китаплар язарга вакытым бар, – дип, юбиляр парламент рәисенә соңгы вакытта чыккан китапларын бүләк итте.

Сессиядә республиканың эчке эшләр министры Артем Хохорин узган ел буенча хисап тотты. Ул үз чыгышында әйткәнчә, Татарстан Россиянең иң имин төбәкләренең берсе булып кала. Мондый вазгыять республикага чит ил инвесторларын һәм туристларны җәлеп итәргә мөмкинлек бирә.

– Былтыр үз алдыбызга җинаятьләр санын арттырмау бурычын куйган идек. 2016 ел нәтиҗәләре буенча, җинаять очраклары 7 процентка кимеде, – диде Артем Хохорин.

Былтыр соңгы 12 ел эчендә балигъ булмаганнар катнашындагы хилафлыклар иң аз күләмдә ачыкланган.

Күп кеше катнашындагы биш меңнән артык иҗтимагый-сәяси, мәдәни һәм спорт чаралары, шул исәптән Дәүләт Думасына сайлаулар белән FIFA Конфедерация Кубогына жирәбә салу да тәртип ягыннан тыныч кына узган. Монда видеомониторинг системасының да өлеше зур. Татарстанда хокук сакчыларының 8000 видеокамерасы урнаштырылган. Алар ярдәмендә ярты мең җинаятьнең очына чыга алганнар.

Былтыр берничә җинаятьчел төркем кулга алынган, алар арасында талау һәм урлашу белән шөгыльләнгән «гастролер»лар да бар.

Исегезгә төшерәбез, былтыр Иске Татар бистәсендәге зиратта вандаллар йөзләп кабер ташына зыян салган иде. Депутат Илшат Әминов бу җинаятьнең тикшерелү барышы белән кызыксынды.

– Кызганыч, ул әле ачыкланмады. Без оператив-тикшерү төркемен көчәйттек, әмма сезне әлегә берни белән дә сөендерә алмыйм, – дип белдерде Артем Хохорин.

Депутатлар сорауларны күп яудырды. Әйтик, Анастасия Исаева әйтүенчә, соңгы арада матбугат чараларында кешеләрнең күпләп сугышулары турында хәбәрләр еш чыга.

– Халык, 90нчы еллар кире кайта, дип пошаманга калып бара. Бу, дөрестән дә шулаймы? – дип, борчуын җиткереп сорады депутат.

Министр әйтүенчә, 90нчы елларның кайтуы турында сүз дә була алмый, төркемнәр (группировкалар) буенча система камил эшли.

– Дөрес, җинаятьчел мохиттә үзгәрешләр, республикада каракларның үз идеологиясен булдыру омтылышы күзәтелә. Без болар турында беләбез һәм шөгыльләнәбез, – диде Хохорин.

КПРФ фракциясе әгъзасы Артем Прокофьев әйтүенчә, Эчке эшләр министрлыгы аларның партиясенә митинглар һәм йөрешләр үткәрергә еш кына рөхсәт бирми.

– Шул ук вакытта студентларның төрледән-төрле чаралары, «Үлемсез полк» үткәрелә. Ике яклы стандартлар эшкә җигелә дигән сүзме бу? – дип, депутат, МВДның КПРФка мөнәсәбәте үзгәрмәдеме, дип сорады.

Артем Хохорин аңлатканча, митинг үткәрүгә рөхсәтне Эчке эшләр министрлыгы түгел, муниципаль хакимият бирә.

Бу урында Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев сүз алды. Ул, депутат Прокофьевка шелтә белдереп, «Үлемсез полк»ны гадәти митинглар белән чагыштыру әхлак ягыннан дөрес түгел, диде.

– Нинди партиядә булуына карамастан, маршта барлык катлау кешеләре катнаша. Бу изге эш, – диде Минтимер Шәрипович.

Депутатлар Татарстанның азык-төлек куркынычсызлыгы турындагы закон проекты буенча да бик актив рәвештә фикер алышты. Мондый документ халыкны барлык төрдәге ризыклар белән теләсә кайсы вазгыятьтә тиешле күләмдә тәэмин итүне күздә тота. Азык-төлек куркынычсызлыгы турындагы закон Мәскәүдә, Санкт-Петербургта, Ульяновск, Саратов, Рязань өлкәләрендә кабул ителгән инде.

Депутат Артем Прокофьев әйтүенчә, җәмәгатьчелек бу законны 25 ел буе, Россиягә чит илләрдән азык-төлек чамасыз рәвештә керә башлаганнан бирле көтте.

Депутат, «Чаллы икмәге» предприятиесе җитәкчесе Рафаэль Юнысов әйтүенчә, читтән карaганда, республиканың азык-төлек индустриясендә бар да ал да гөл. Әмма бу шулай тоела гына икән.

– Соңгы арада федераль сәүдә челтәрләренең монополия урнаштыруы күзәтелә. Товар җитештерүче үз продукциясен шул кибет киштәләрендә тәкъдим итәргә теләсә, ташламалар куярга тиеш. Әмма федераль закон буенча икмәк эшләнмәләренә ташлама куюны таләп итәргә ярамый. Мондый шартларда товар җитештерүчеләргә эшләүнең бер мәгънәсе дә калмый бит. Син үз ташламаларың белән федераль челтәрләрнең позициясен көчәйтеп, үз төбәгеңнең кибетләрен, киресенчә, кыен хәлдә калдырасың, – дип борчуын җиткерде Рафаэль Юнысов.

Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, продукциягә ихтыяҗ зур булсын дисәң, бәя белән сыйфат турында ныгытып уйларга кирәк. Парламент рәисе, закон проектын икенче укылышка әзерләгәндә, мәсьәләне һәръяклап дикъкать белән өйрәнергә чакырды.

«Барс канатлары» Россия чемпионатына әзерләнә

18-21 февраль көннәрендә Казанда беренче тапкыр инвалид коляскасында баскетбол буенча Россия чемпионаты узачак. Ярышлар «УНИКС»-ның Васильево бистәсендәге кунакханә-спорт комплексы базасында була.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотоархивыннан

Алисә САБИРОВА

Ил чемпионы исеме өчен көрәшергә Мәскәү, Санкт-Петербург, Төмән, Ульяновск, Ижау, Чаллы шәһәрләреннән 120гә якын спортчы киләчәк.

Казанның «Барс канатлары» да Яңа ел бәйрәмнәреннән соң ярышларга ныклап әзерләнә башлаган. Физик мөмкинлекләре чикле булуга карамастан, атнасына биш тапкыр шөгыльләнергә вакыт таба алар. Соңгы өч елда «Барс канатлары» ил буенча икенче урында бара. Быелгы максатлары – беренчелеккә чыгу.

– Турнирга җитди әзерләнәбез, җәрәхәтләр юк. Максатыбыз бер генә – I урын. Төп көндәшебез Санкт-Петербург шәһәренең «БасКИ» командасы. Без алар белән еш бәрелешәбез, ләкин әлегә җиңгән юк. Егетләр тырыша, әзерлек дәрәҗәсен уен күрсәтер, – ди команданың тренеры Василий Кочетков.

Җитди ярыш алдыннан «барс»лыларның капитаны Андрей Чугунов та көндәшләренең көчләрен югары бәяли.

– Без Татарстан буенча гына җыелган команда, ә «БасКИ»ларны Россия җыелмасы дип әйтсәк тә була. Анда бөтен ил буенча иң көчле спортчылар тупланган. Тагын шунысы бар, безгә озын буйлы уенчылар җитми. Алардан уенга өч-дүрт озын буйлы спортчы чыкса, бездән андыйлар бер-ике генә. Җиңүгә шул комачаулый да инде. Безгә җан атып торыгыз, туган як диварлары ярдәм итәр дип уйлыйм, – диде Андрей Чугунов.

Спортчылар һәрберсе үзенең үзенчәлегенә карап көйләнгән Германия һәм Бөекбританиядән кайтарылган махсус коляскаларда шөгыльләнә. Алар гади инвалид коляскасыннан шактый аерыла: ул титан һәм алюминий эретмәләреннән ясалган, тәгәрмәчләре янтаеп тора, авырлыгы да нибары 9-11 килограмм гына.

Ярышлар көн саен иртәнге 8.00дән кичке 20.00гә кадәр дәвам итә. Чемпионат барышын теләгән һәркем күзәтә алачак.

«Барс канатлары» командасы 2009 елда ул вакыттагы Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев ярдәме белән оешкан.

«Республикада милләтара климат «йомшарды»

Татарстан халыклары ассамблеясының узган елгы эшчәнлегенә багышланган утырышта Ассамблея җитәкчесе, Татарстан Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин шулай дип белдерде. 2016 елның төп сәяси вакыйгаларын атап киткәннән соң, ул быел 22 апрельдә III Татарстан халыклары съездына әзерлек эшләре башлануын хәбәр итте. Аны оештыру комитеты төзегән, рәисе итеп Фәрит Мөхәммәтшин үзе билгеләнгән.

addnt.ru

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА

– Республикада һәр ун ел саен Татарстан халыклары съездын уздыру традициягә кереп бара. Анда милләтара тынычлыкны саклау һәм ныгыту мәсьәләләре карала. II съезддан соң Татарстанда этно-мәдәни хәрәкәттә уңай үзгәрешләр барлыкка килде. Быелгы съезд да нәтиҗәле эшләр дип көтәбез. Аның эшендә республикада яшәүче барлык 173 милләт вәкиле катнашачак. Милләтләр арасындагы дуслык – республиканың төп сәясәте. Тынычлыкны, үзара аңлашуны тәэмин итүче дәүләт программалары эшләп килә. Алар нәтиҗәсендә ышаныч капиталы, хакимияткә, муниципаль хакимияткә ышану капиталы тупланды. Республикадагы милләтара климат та «йомшарды». Татарстанда яшәгән бер генә милләт вәкиле дә үзен чит тоймаска тиеш, – диде ул, утырышны ачып.

МИГРАНТЛАРНЫҢ САНЫ АРТА

Соңгы 25 елда Ассамблеяда теркәлгән милли-мәдәни автономияләр тугыздан 36га арткан. Быел тагын абхазлар кушылырга тора.

– Бүгенге көндә оешмабыз үз канаты астына 200дән артык җирле һәм төбәк милли-мәдәни иҗтимагый оешмаларны ала. Татарстан – социаль һәм икътисади яктан алга киткән төбәк, шуңа да биргә килүчеләр күп. Узган елны республикага килгән 250 мең чит ил гражданы миграция теркәве узган. 2015 ел белән чагыштырганда, бу 7 процентка артыграк. Аларның 40 проценты республикага эш эзләп килә. Калганнары укырга, медицина ярдәме алырга килә. Күпчелеге Татарстанда гаиләләре белән яшәп тә кала, – дип сөйләде Ассамблея Советы башкарма комитеты җитәкчесе Николай Владимиров.

Халыклар дуслыгы йорты чит ил кешеләре өчен проблемаларны хәл итү урыны да булып тора. Милли-мәдәни автономия җитәкчеләре ватандашларын берләштерергә тырыша, аларга яңа урында җайлашырга ярдәм итә. Үзбәкләр оешмасы җитәкчесе Абдуманоб Абдусаттаров үзенең урынбасары белән Халыклар дуслыгы йортында 1500 кешене кабул иткән. Шул рәвешле ватандашларының миграция, эш табу, хезмәт хакы алу кебек проблемаларын хәл иткәннәр.

– Яшьләр белән дә актив эш алып барырга тиешбез. Бүгенге көндә югары уку йортларында 100дән артык илдән 9000 студент белем ала. Аларга яңа социаль-мәдәни мохиттә тизрәк җайлашырга булышлык күрсәтергә кирәк, – ди ул.

АССАМБЛЕЯДА ЯҢА ВӘКИЛЛЕКЛӘР

Татарстан Халыклары дуслыгы йорты җитәкчесе Ирек Шәрипов сүзләренчә, ассамблеяның уңышлы эшләп килгән проектлары шактый.

– Быел «Татарстан – уртак йортыбыз» этномәдәни фестивале зур масштабта узды. Иҗади конкурста катнашучыларның саны елдан-ел арта. Узган ел аларның саны 2000гә җитте. «Радуга-Салават күпере» фестивале дә популярлаша бара. Аның сайлап алу турларында 1800 бала катнашты. «Нәүрүз» бәйрәме 6000 кунакны җыйды. Аны быел Казан ипподромында үткәрергә җыенабыз. Май чабу бәйрәме 25 февральдә «Әкият» курчак театры янындагы Боз шәһәрчегендә узачак. «Мәдәниятләр мозаикасы» фестивале дә истә калырлык булды. Халыклар дуслыгы йорты егерме күргәзмә оештырды, аларда 3000 кеше булды, – дип сөйләде Ирек Шәрипов.

Россиядә быел беренче тапкыр узган зур масштаблы чара – «Этнографик диктант» язуны да искә алып үтте ул. Аның нәтиҗәләре буенча, иң югары күрсәткечне Татарстан халкы җыйган: 81,3 балл. Россия буенча уртача балл – 54.

Татарстан халыклары ассамблеясының порталы да популярлаша бара. Порталга керүчеләрнең саны 40 процентка арткан. 2016 елда, «Татарстан» телерадиокомпаниясе белән берлектә, «Национальные вопросы и ответы» тапшыруы чыга башлады. Ул да телевизор караучыларда кызыксыну уяткан.

Утырыш ахырында Фәрит Мөхәммәтшин Мөслим, Чүпрәле һәм Кукмара районнарында Татарстан Халыклары ассамблеясы вәкиллекләре ачылуын хәбәр итте. Бүгенге көндә республикада Ассамблеяның ике филиалы һәм тугыз вәкиллеге эшли. Халыклар дуслыгы йортлары Чаллы, Тәтеш, Түбән Кама, Менделеевск, Нурлат һәм Лениногорскида уңышлы эшләп килә.

«WORLDSKILLS» КӨНДӘЛЕГЕ

Каланы чәчәккә төрәләр

Таш каланы алар хуш исле чәчәккә күмәргә, асфальтны ертып, төрледән-төрле агачлар үстерергә сәләтле. Сүзем ландшафт дизайнерлары хакында бара.

Алисә САБИРОВА

Лубян урман-техник көллияте студентлары (Кукмара районы) Станислав Козырев белән Ульяна Селюнина әле беренче курста укуларына карамастан, республика күләмендә узган «WorldSkills» эшче һөнәрләр чемпионатында I урын алуга ирешкәннәр. Республика буенча II урынны яулаучылар да әлеге көллият укучылары.

Станислав – Лубянның үзеннән. Дуслары, туганнары шушы көллияттә белем алган, ул да мәктәпне тәмамлагач, озак уйлап тормаган.

– Хәзерге вакытта популяр, бик кирәкле һөнәрләрнең берсе бу. Хезмәт хакы да яхшы безнең. Мин, авылда туып-үскәнгәдер инде, җир эшен яратам, – диде егет.

Ульяна исә биргә Удмуртиянең Можга шәһәреннән килгән.

– Мин һәрвакыт иҗат белән кызыксындым, матурлык тудырырга яратам. Иптәш кызым белән алдан сөйләшеп, монда укырга кердек. Укытучылар да, белем бирүләре дә бик ошый. Хәзерге вакытта «WorldSkills»ның төбәкара чемпионатына әзерләнәбез. Аның өчен көненә дүрт-биш сәгать вакыт китә. Көллиятне тәмамлагач, Казан дәүләт төзелеш институтына шушы ук белгечлек буенча укырга керәчәкмен, – диде Ульяна.

Чемпионатның «Ландшафт дизайны» компетенциясе буенча республика эксперты урынбасары, көллияттә махсус дисциплиналар укытучысы Наталья Сиражетдинова сүзләренчә, төбәк этабында студентларга 15 сәгать эчендә 14 квадрат метрлы мәйданчыкны чәчәк түтәлләре белән бизәргә туры килгән.

– Алар чәчәкләрдән, төрле корылмалардан торган түтәлләр ясады. Әйтик, бер җирдә чәчәк түтәлен кирпечтән өяргә, икенче җирдә табигый таштан төзергә кирәк иде. Шулай ук түшәлгән таш, чуерташ, геопластика куллану да таләп итеп куелды, – диде Наталья Сиражетдинова.

Алдан әйтеп киткәнебезчә, хәзер команда Мәскәү янында узачак төбәкара ярышларга әзерләнә. «Ландшафт дизайны» буенча илнең иң яхшы 15 командасы Россия этабына чыгачак. Алардан ил җыелмасына бары биш төркемне генә сайлап алачаклар. Кыскасы, үз эшеңнең остасы икәнеңне дәлилләү өчен, егетләр һәм кызларга әле җиде иләк аша узарга кирәк булачак.

– Әлегә без лидерлар рәтенә кермибез. Студентлар заманча кораллар белән эш итә белми. Республика көллиятләрендә алар, гомумән, юк. Хәзер дәүләт эшче һөнәрләренә игътибарны арттырды. Якын арада безгә дә WorldSkills стандартларына туры килгән техника кайтачак, – диде Наталья Сиражетдинова.

Көллият күптән түгел үзенең 95 еллык юбилеен билгеләп узды. Шушы вакыт эчендә уку йорты 9500 студент укытып чыгарган. Хәтта Бөек Ватан сугышы вакытында да белгечләр әзерләү эшен туктатмаган. Студентларның 70 проценты, укуны тәмамлауга, үз белгечлеге буенча эшкә урнаша. Ел саен көллияткә 120 бюджет урыны бүлеп бирелә.

АНА

Бала хәсрәтен дошманыңа да күрсәтмәсен, ди безнең халык. Бәгырь җимешләрен югалтканнар күңеленнән күз яшьләре белән бергә саркып чыккандыр бу гыйбарә. Мең газаплар белән тапкан, татлы төн йокыларыңны калдырып баккан өметең сүнеп, дөньяда яшәүнең мәгънәсе калмаганда тугандыр бу изге теләк…

Йолдыз ШӘРАПОВА

ӘНИ БУЛДЫМ ДИГӘНДӘ ГЕНӘ…

Барлык хатын-кызлар шикелле үк, Полина да әни буласын көнләп түгел, сәгатьләп саный. Беренче сабыйлары бит. Табиблар, малай туачак дип, булачак әти Александрны да сөендереп куялар.

Сабыеның тәүге авазын ишеткән мизгелдә Полинадан да бәхетле кеше булмагандыр. Тик баласына күкрәк сөте белән тамчылап тормыш биргән ул бәхетле мизгелләр төш шикелле эреп юкка чыгалар. Беркөнне иртән ашатырга алып килгәндә, нарасыеның чигә тирәсендә сыдырылган эзләр, каткан кан тамчылары күреп, яшь ана тәмам пошаманга төшә. Шәфкать туташы, дорфа гына: «Тимә, актарма!» – ди дә баланы алып чыгып та китә. Көтеп алынган улын соңгы тапкыр күрермен дип башына да китерми яшь ана. Иртәгесен аңа баласын инде кертмиләр. «Үлде», – диләр, тавышларына кызгану, үкенү төсмерләре дә чыгармыйча. «Ничек үлде? Кая куйдыгыз улымны?» – дип ачыргалана яшь ана. Үзенең дә хәле хәл булып, кайгы да тәмам аяктан екканга, ул тәүге сабыен җирләшә дә алмый. Соңыннан барысы да ачыклана. Бала тудыру йортының бер хезмәткәре үзенең саксызлыгы аркасында бер арба нарасыйны еккан икән. Шул бәхетсезләр арасында аның улы да булган…

КАЗАХ ХАТЫНЫН КЫЗГАНЫП…

Полинага кабаттан ана булу бәхете насыйп була. Бу юлы да тупырдап торган малай. Тегесен дә тапмас борын югалткач, монысын бик яратып, назлап үстергәнгәме, Сережа үзе дә гаиләнең өметен акларга тырыша. Болай да кайгы-хәсрәтне күп күргән әти-әнисен мәшәкатьләп тормый, авырмый гына, таза бәдәнле егет булып үсә. Мәктәптә дә әти-әнисенә борчу китерми. Футбол уйнаганда канаган борыннар, сыдырылган тез башларын санамаганда, балачак тыныч кына үтеп китә. Егетнең солдат булып, Ватан алдындагы бурычын үтәр вакыты да җитә. Бердәнбер малайларын солдаттан алып калырга мөмкинлекләре булса да, егет сүзе бер була: «Мин бармасам, ул бармаса, илебезне кем саклар?» 1999 ел була бу. Пешекче булып, солдатларга тәмле аш пешереп ашатып, хезмәтен үтәгән егетне (аның гражданлык һөнәре дә шул була), инде кайтыр вакыты җитеп килгәндә, хәрби хәрәкәтләр барган Чечняга җибәрәләр. Ә анда… алар утырган автомобиль минага эләгеп шартлый. «Бердәнберебез менә кайта, менә кайта!» – дип көннәрен санап көткән әти-әнигә кайгылы хәбәр җиткерәләр. Ростовтан цинк табут биреп җибәрәләр. «Ачмагыз!» – дип катгый итеп әйтсәләр дә, ана улының йөзенә соңгы тапкыр карый алмый кала димени?! Ачалар, ә анда Сережа түгел… бер казах егете ята. Язмышлары белән ризалашырга туры килә Васильевларга. Шушы чит-ят егетне (ул да кемнеңдер газиз баласы бит!) кадерләп күмәләр, каберенә барып йөриләр. Ул чакларда: «Минем баламның сөякләре кай җирдә ята икән инде?» – дип, тагын да ныграк сызланып куя ана йөрәге… Үзенгә түгел, улын югалткан казах хатынын кызганып та коя күз яшьләрен.

КҮҢЕЛ ДӘВАСЫ – КҮКЧӘЧӘК

Дошманыңа да күрсәтмәсен дип бик әйтерсең… Икенче улын югалту ачысыннан тәмам исергән Полина ханым, азрак күзе ачыла башлагач, балалар йортларындагы ятимнәр янына барып йөри башлый. Шунда бер кызны күргәч тә аның йөрәге, ничектер, кабат дертләп кабынып китә. Бу сабый гына түгел, башка ятимнәр дә сыйлансын, уларыма дога булып барсын дип, капчык тутырып күчтәнәчләр ташый. Эшмәкәр хатын бит ул, үзенең шәхси предприятиесе бар. Уллары Сережа үскәндә үк, оныкларга иркенлек булсын дип, сарай хәтле зур өй җиткерәләр. Бу өйнең һәр почмагыннан үле тынлык карап тора башлагач, түзми, күңеленә кергән шушы нәни кызчыкны үзенеке итәргә теләп, тиешле документларны әзерләп, өйләренә алып кайта. Ире Александр да каршы килми. Шулай итеп, Васильевларның зур өе ике яшьлек Аделинаның чыр-чуына күмелә. Ләкин күкчәчәк кебек нәфис бу кызчыкны табигать үзенчәлекле итеп яраткан: кул һәм аяк бармаклары бөтәннәрнеке шикелле бишәү түгел, ә алтышар. Хастаханәләрнең хирургия бүлекләре, катлаулы операцияләр… һәм менә кызның кул бармаклары гадәттәгечә бишәү булып кала. Кызын хирург кулына тапшырганда нинди хисләр кичергәнен Полина үзе генә белә. Шундый ук операцияне әле аяк бармакларына да ясатасылары бар, алтынчы бармак кызга йөрергә комачаулый, аксата. Аделинага хәзер инде 12 яшь. Чибәр кыз булып үсеп килгән чагы.

Полина һәм Аделина белән мин Чаллы шәһәрендә тәрбиягә бала алган гаиләләрнең җәйге ял сменасында таныштым. Күпме кайгылар күреп тә, яшәү дәртен югалтмаган, күңелен суытмаган, киресенчә, йөрәк җылысын бер сабыйның бозланган җанын эретергә бирә алган бу ханымга сокланып туя алмадым. Ана булуның, кеше булып калуның иң матур үрнәге ич ул, исән чакта һәйкәл куярлык гали зат. Бу гаиләнең аянычлы тарихын белгәч, Полинадан сак кына: «Аделинага иптәш алып кайтырга уйламыйсызмы соң?» – дип сорадым. Ул юк димәде, моңсу гына елмайды да: «Андый уебыз да бар», – диде. Димәк, тиздән, бик тиздән тагын бер ятим сабыйга бәхет кояшы елмаячак, җылы кочак ачылачак…

СОРАУ-ҖАВАП

«Ашыгыч ярдәм» хезмәтенә карата ике соравым бар иде. Еш кына «Ашыгыч ярдәм» хезмәте кеше көткән вакытка тиз генә килеп җитә алмый. Килгәч тә, кирәкле адрес буенча фатирга узганчы, шактый вакыт уза. Гадәттә, ишегаллары тулы машиналар. «Ашыгыч ярдәм» хезмәте машиналарына юлда комачаулаган автомобильләрне бәрдерергә дә ярый дигән закон кертергә уйлыйлар дип ишеттек. Татарстанның «Ашыгыч ярдәм» хезмәте җитәкчеләре үзләре бу хакта нәрсә уйлый икән?

Икенче сорау: *Татарстанда ашыгыч ярдәм күрсәтә торган мотобайклар бар дип ишеткән идек. Мотобайкларга медицина ярдәме күрсәтү җайланмалары сыямы?*

Айназ Вәлитов,
Яшел Үзән.

cache.readovka.ru

Татарстанның «Ашыгыч ярдәм» хезмәте баш белгече **Марина ВОРОНЦОВА** җавап бирә.

– Ишегалларына керү авыр, сүз дә юк. Еш кына «Ашыгыч ярдәм» хезмәте машинасына дөрес урынга куелмаган автомобильләр комачау итә. Әмма машиналарны бәрдереп китәргә рөхсәт бирүгә караганда, дөрес парковка проблемасын күтәрсәләр, отышлырак булыр иде, минемчә. Тиешсез урынга машина куйганнар өчен штрафларны катгыйландырырга кирәктер, бәлки.

Икенче сорауга килгәндә, ашыгыч ярдәм мотоцикллары җәйге режимда эшли. Һәр мотобайкның өч кейсы бар. Аларга дефибриллятор, кислород баллоны, кислород битлеге, медикаментлар белән сумка, глюкометр, тонометр һәм башка кирәкле җиһазлар урнаштырылган. Мотобайклар тиз йөри. Алар машина тугыз минутта узган араны алты минутта үтә. Шул яктан мобиль булып санала. Аннары машина үтә алмас тыкрыкларга керә алуы белән дә отышлы. «Ашыгыч ярдәм» бригадасы килеп җиткәнче, мотоциклдагы фельдшер, зыян күрүчене карап чыгып, тиешле ярдәмне күрсәтә. Узган ел җәйге чорда мотоцикллар 400дән артык чакыруга бардылар.

СӘНГАТЬ ӘХРАМЫ

Автор фотолары

Дөньяны ачу үзеңне ачудан башлана

Татарстан һәм Россия Рәссамнар берлеге әгъзасы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Хәмзә Шәрипов интарсия техникасы буенча осталык дәресе бирәчәк, дип хәбәр салуга, Байназар Әлменов исемендәге 3нче Балалар сәнгать мәктәбе укучылары сәгате-минуты белән килеп тә җитте.

Расиха ФӘИЗОВА

Осталык дәресе башлангачы, рәссам башта кунакларны «Шәһри Казан» редакциясенең күргәзмәләр залында барган үзенең шәхси күргәзмәсе белән таныштырып чыкты. Балаларның күзләре кызганнан-кыза баруын чамалавы кыен түгел иде. Чөнки рәссамның эшләре, нигездә, нәкъ менә ул өйрәтәчәк техникада башкарылган. Бу алымны кулланып, драптан, катыргыдан йөзләрчә паннолар, картиналар иҗат иткән, шул эшләре белән күпсанлы шәһәр, республика, гомумроссия, халыкара күргәзмәләрдә катнашкан рәссам Хәмзә Шәрипов. Шуңа күрә дә ул аның рәтен, серләрен кемгә карагандa да яхшырак белә. Әйтик, ни өчен төсле кәгазь түгел, ә катыргы? Монысына да ул эшли-эшли төшенгән. Кәгазь, кискәндә, теткәләнеп бетәргә дә мөмкин, ә катыргыда бу күзәтелми, аннан аның төсе дә тотрыклырак, эш тә затлырак килеп чыга.

Бу алымның үзенчәлеге шунда ки, беренчедән, берьюлы бернечә картиналы буласың, икенчедән, аппликация эшләгәндә, һәр бизәк берсе өстенә икенчесе ябыштырыла барса, биредә һәр деталь бер-берсенә керешеп, берегеп бара. Җитмәсә, бүген генә уйлап табылган техника түгел, ә борынгыдан килгән алым булуы белән дә кызык әле ул. Безнең борынгы әби-бабаларыбыз, бу техниканы кулланып, киез келәмнәр эшли торган булганнар. Монысын Алтайның Пызырак курганнарында табылган ядкярләргә таянып әйтәбез.

Эш өчен кирәк әйберләрне, ягъни өч-дүрт төстәге катыргы, канцелярия пычагы (кечкенәсе), җилем-карандаш, скотч, тасмалап киселгән бик юка кәгазьне балалар үзләре алып килде. Иң башта булачак картинаның эскизы ясалды, аннан өч-дүрт табак төсле катыргы өстенә шул үлчәмдәге эскизны куеп, барысы бергә – селкенмәслек итеп ян-ягыннан скотч белән беркетелде. Аннан канцелярия пычагы белән рәсемнең детальләре киселә. Моннан соң төсләрне ярраштырып, әлеге детальләрдән яңа композицияләр җыясы гына кала. Башта ничә катыргы беркетелгән булса, шуның кадәр яңа эш җыела. Әзер композицияләрнең арткы ягыннан, детальләр ялганган җирләрен җилем һәм тасма итеп телемләнгән юка кәгазь белән ябыштырабыз. Эш барышын санап чыкканда гына бик җиңел кебек, әмма балаларга ике сәгатьтән артыграк тырышырга туры килде. Нәтиҗәдән барысы да канәгать иде. Хәтта арада иң тиктормас булып тоелган Рома Башлыков та басылып эшләде, кызыксынып, сорау арты сорау яудырды рәссамга.

– Авыр, әмма кызык. Мин әле моны янадан да эшләячәкмен, – диде ул.

– Бу техника бөтенләй уйламаган өр-яңа эшләр килеп чыгуы белән игътибарны җәлеп итә икән. Без моны үзебезнең дәресләрдә дә дәвам итәчәкбез әле, – диде сәнгать мәктәбе укучысы Дарина Ильясова да, рәссамга рәхмәтләрен җиткереп.

Батырлар сынала

18-19 февраль көннәрендә Биектау бистәсендә «Сабантуй» журналы призына яшүсмерләр арасында татарча көрәш буенча республика беренчелеге узачак. Биредә 15-16 яшьлек егетләр бил алыша.

Татарстан Республикасының яшьләр эшләре һәм спорт министры урынбасары Хәлил Шәйхетдинов сүзләренчә, хәзерге вакытта республикада 135 спорт төре бар. Ел саен 800дән артык спорт ярышлары үткәрелә. Хәзерге вакытта төп максат – яшүсмерләр арасындагы татар көрәшен югары дәрәҗәдә оештыру.

– Тарихка күз салсак, бу ярыш 1973 елда, ул вакытта әле «Яшь ленинчы» исемен йөрткән «Сабантуй» журналы тарафыннан башланып киткән иде. Бу безнең күркәм традиция. Күптән түгел генә «Ватаным Татарстан» журналы үткәргән көрәш буенча Муса Җәлил турниры узды. 3-4 март көнне 17-18 яшьлек егетләр «Татарстан яшьләре» газетасы призына ярышачак. Массакүләм мәгълүмат чаралары тарафыннан көрәшне күтәру очраклы түгел, ул безнең спорт төре булудан тыш тарихыбыз, мәдәниятебез дә әле, – диде Хәлил Шәйхетдинов.

Турнирның җиңүчеләре 17-18 мартта Башкортстанның Стәрлетамак шәһәрендә узачак Россия беренчелегендә катнаша. Бу ярышларны да җиңгән егет спорт мастерына кандидат исемен алачак. Җиңүчеләрне шулай ук «Сабантуй»ның тышлыгында күреп булачак.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Чулпан Йосыпова:

«Мин вакытны куалыйм»

Теге яки бу артист белән әңгәмә корганда, аның эшләгән эшләре, башкарган җырлары турында сөйләшүдән бигрәк, кешенең эчке дөньясын ачасы, тормышка карашын беләсе килә. Чулпан Йосыпова белән интервьюга барганда, мин аның турында бик аз мәгълүматлы идем, чөнки моңа кадәр җырчы белән очрашырга туры килсә дә, кара-каршы утырып аралашканыбыз булмады. Тамашачы арасында, Чулпан – супер популяр, дип, аны күкләргә чөеп мактау да дөрес булмас иде. Әмма шунысы ачык: тырыш, максатчан, ярдәмчел һәм ачык күңелле кызның ялыйсы үрләре, җырланасы җырлары алда әле.



Зөһрә САДЫЙКОВА

– Мин Пермь ягының Барда кызы, – дип, сүзне үзе белән таныштырудан башлады ул. – Казанга бик тә киләсем килгәнлектән, 10-11нче сыйныфларны берьюлы укып, мәктәпне алтын медальгә тәмамладым. Аннан соң әти-әнием белән бергә күченеп килеп, укырга кердем. Әтием Әүхәт гомер буе колхоз рәисе булып эшләде, әнием Илсөяр 25 еллар элек Казан филармониясендә солист булып эшләгән. Аннан соң әтием белән кавышып, кабат туган якларына кайтып киткән. Бертуган сеңлем театр училищесының соңгы курсында укый.

– Казан тамашачысы каршында башкарган беренче җырыңны да хәтерлисеңдер әле.

– 2010 елда мин «Татар моңы»нда катнаштым. Зур сәхнәгә чыгуым да нәк шул вакытта булды. Ул чагында миңа 15 яшь иде. Әгәр үземә танылу алып килгән җыр турында әйтсәк, ул 2011 елда башкарылган «Кыр казы» (Оскар Усманов көе, Дания Гайнетдинова сүзләре) иде.

– Эстрадада берничә еллар иҗат итеп тә, Казан сәхнәсендә сольный концертлары чыгыш ясарга куркып торган җырчылар бар. Ә филармониядә үз тамашачыңны җыеп, беренче концертыңны биргәндә сиңа нибары 17 яшь кенә булган. Ул чакларда, бу яшь-яшь кызга кем ярдәм итә икән, дип аптырачылар да булды.

– Менә хәзер үзем дә шаккатып уйлап утырам – ничек җөрьәт иткәнмен икән? Ул вакытта сценарийны да үзем язган идем бит. Кызыксынучыларга җавабым шул – иҗатымның алдагы елларында төп ярдәмчем, киңәшчем, продюсерлар башкара торган зур, җаваплы эшләрне үз өстенә алучы кешем әтием булды.

– Чулпан, сәхнәдә талант белән бергә әрсезлек тә кирәк, диләр. Ә син үзең ничек уйлыйсың?

– Мин, әлбәттә, беренче чиратта тавышка, җыр сүзләренә игътибар бирәм. Күзгә артык бәрелмичә, тыныч кына иҗат итүне, тугры тамашачымның сафларын тагын да арттыруны максат итеп куям. Дөрес, максатка ирешү өчен әрсез булсаң, яхшыдыр, әмма аннан да бигрәк, акча кирәк. Шундый матур тавышлы яшьләр бар, әмма зур сәхнәләргә чыгарга аларның финанс мөмкинлекләре юк. Шунысы кызганыч. Клип төшерүме, җыр яздырумы, радиоларда ротациями, концерт оештыру булсынмы – барысы да акчага килеп төртелә.

– Тамашачы сине бераз югалтып та торды бит әле.

– Әйе, кияүгә чыккан, баламны көткән вакытлар иде ул. Ике ел дәвамында клипларым төшерелмәде, радиоларда яңа җырларым яңгырамады, катнаш концертларда да сирәк чыгыш ясый идем, чөнки бу вакытымны мин тулысы белән гаиләгә багышладым. Хәзер бик үкенәм шуңа. Аннан соң эшкә яңадан тотыну, иҗатка кереп китү бик авыр булды. Ә эшемне бик яратам, үземне башка өлкәдә күз алдына да китерә алмыйм. Музыкаль белемнән кала, юристлыкка да укыдым. Әтиләр: «Синең зур урыннарда эшләрлек мөмкинлегең бар», – дисәләр дә, үземне нәкъ менә шушы өлкәдә бәхетле хис итәм. Әлегә үземне популяр җырчы дип санамыйм, булганына шөкер итәм, әмма алда барысы да яхшы булачагына өметләнәм.

– Чулпан, узган ел тормышыңда сөенечле вакыйга – әни булу бәхетен татыдың. Улың туу тормышка карашыңны үзгәрттеме?

– Улым минем куанычым, шатлыгым. Нинди генә начар хәбәр килеп ирешсә дә, аны кочагыма алып яраткач, бөтен борчуларым юкка чыга. Аннан соң балам туу тагын да тырышлыбрак эшләргә этәргеч бирде. Аны алып кайтканның өченче атнасында ук, җырлар яздырып, концертларда катнаша башладым. Хәзер дә концертлар белән гел йөреп торабыз. Улымны карарга әни булыша. Үземнән бер дә калдырмас идем, әмма эшләмичә дә булмый.

– Синең Казан театр училищесында укытуың турында да күпләр белмидер дип уйлыйм. Шундый җаваплы эшкә алынырга ничек курыкмадың?

– Бу минем, кечкенә генә булса да, җиңүем. Сентябрьдән студентларга вокал дәресләрен бирә башладым. Башта егетләр һәм кызлар да, башка педагоглар да мине укытучы буларак кабул итмәде. Үзем дә дулкынланган идем, чөнки студентлар арасында яшьтәшләрем дә бар. Хәзер барысы да җайланды. Дәресләр бирәм, шул ук вакытта үз өстемдә дә эшлим. Белемне һәрвакыт камилләштереп торырга кирәк дип саныйм.

– Синең тавышыңны Татарстанның халык артисты Әлфия Авзалованыкына охшаталар. Ул башкарган «Шиңгән чәчәкләр» җырына да яңа сулыш өреп, тамашачыга тәкъдим иттең. Шундый легендар җырчы белән чагыштырулары сиңа ошыймы, әллә күңеленне төшерәме?

– Хәмдүнә Тимергалиевага да охшаталар әле минем тавышны (*көлә*). Шатмын, әлбәттә, әмма махсус берсенә дә охшатып җырларга тырышмыйм. Үзем аларның тавышына бер дә охшатмыйм. Күңелемнән нинди моң чыга, шуның белән җырлыйм. Мин төрле жанрларда башкарам – халык җырларын да, эстрада, джазны да җырлыйм.

– Син бит әле туйлар, мәҗлесләр дә алып барасың. Шушы эшеңдә үзеңә нинди таләпләр куясың?

– Беренчедән, килделе-киттеле, «билдән түбән» мәзәкләр сөйләмим, андый мәҗлесләрдә булганым бар. Алып баручылар өчен оялып, кызарып кайтам. Кыска итәк, ачык күлмәкләр дә кимәскә тырышам.

– Чулпан, мәктәптә ике сыйныфны бергә укып, тизрәк Казанга киләсем килде, дисең. Тамашачы каршында беренче имтихан узуларың да бик иртә иде, аннан соң 22 яшьтә үк вокал дәресләре бирүчеләр дә сирәк була... Гафу ит, ләкин үзеңә вакытны ашыктырасың кебек тоелмыймы?

– Тормышны куалавымны үзем дә аңлыйм. Кечкенәдән үк бик җаваплы булып үстем. Һәрнәрсәне алдан эшли торган кешемен. Мәсәлән, алдагы сыйныфта укылырга тиешле китапларны җәйге каникулларда укып чыга идем инде. Үз алдыма максат куйсам, шуны ахырга кадәр җиткермичә туктамыйм. Бу сыйфат әтиемнән күчкән. Аннан соң холкымда андагы «егетлек» сыйфатлары да чагыла. Кечкенә чакларда аның белән бергә ауга, балык тотарга йөри идем. Руль артына беренче тапкыр утырып каравым да бишенче сыйныфта булды минем. Әниемнән исә тавыш һәм пешеренергә ярату мы алынган. Ул бик матур җырлый. Концертларымда да чыгыш ясаганы булды.

– Ә башка артистларның концертларын карарга яратасыңмы?

– Бик яратам. Филүс Каһировның, Зәйнәб Фәрхетдинованың, Радик Юльякшинның җырлавын хөрмәт итәм.

– Тиздән үзең дә тамашачыга яңа программаңны тәкъдим итәргә уйлыйсың дип беләм.

– Әйе, 23 февральдә Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә бишенче концертым булачак. Шушы ук программа белән республика районнарында һәм Бардада да чыгыш ясаячакбыз. Тамашачы яратып кабул иткән җырлар белән берләттән, концертта яңа иҗат җимешләрем дә яңгыраячак. Моннан кала, дискымны тәкъдим итү, иҗатташ дусларым чыгышы һәм сюрпризлар да көтелә.

Татарстан Язучылар берлегенең Тукай клубында Әзәрбайҗан шагыйрәсе Сона Вәлиеваның «Аразбары» («Араз коймасы») китабын тәкъдим итү кичәсе булды. Шигырьләрне татар теленә шагыйрь Рифат Сәлах тәрҗемә иткән. Аның үз шигырьләре дә Әзәрбайҗанда чыккан шигырьләр антологиясенә кертелгән иде.

Әзәрбайҗан шигырьләре татарча

ЯҢА КИТАП

Тантанага Әзәрбайҗаннан шагыйрь, Бөтендөнья төрки халык язучылар берлегенең Киңәшмә шурасы башлыгы Әкбәр Гошалы белән шагыйрь, язучы, «Каспий» газетасының мөхәррире Фәрит Хөсәен килде.

Китапка кергән шигырьләрне ТР Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, Татарстанның халык артисты Луара Шакирҗан укыды. Кичәдә Татарстанның халык язучысы Рабит Батулла, галим Фоат Галимуллин, ТР халык шагыйре Роберт Миңнуллин чыгыш ясады. Роберт Миңнуллин Рифат Сәлахның оста тәрҗемә итүен билгеләп үтте.

Халыклар дуслыгы йортыннан Әзәрбайҗан милли автономиясе вәкилләренең әзәрбайҗанча җырлар башкарулары һәм биюләре, Татарстанның атказанган артисты Рәсим Низамов җырлары кичәне тагын да җанландырып җибәрде.

Люция ГАЛИМҖАНОВА.

Каләм тарихы ташка басылды

Февраль аенда Казаныбызда янә татар илендә яшәвең белән горурланырга форсат бирә торган ике зур вакыйга – бәйрәм булды. Беренчесе – Татарстан Фәннәр академиясендә Тукай энциклопедиясен, икенчесе – «Татарстан Язучылар берлеге» дигән саллы җыентыкны тәкъдим итү.

Әдәбиятыбыз тарихына багышланган китап бәйрәменең 15 февраль – каһарман шагыйрь Җәлилнең туган көнендә Матбугат йортының бишенче катында, кайчандыр гөрләп торган Тукай клубында, хәзерге «Ногай» кунакханәсендә узуы да юкка түгелдер. Китап узган ел азагында Татарстан китап нәшриятында 2600 данә белән дөнья күргән.

– Мондый китап башка бер генә республикада да юк, бездә генә, – дип шатлыгы белән уртаклашты нәшрият директоры Илдар Сәгъдәтшин.

Язучылар берлеге рәисе Данил Салиховның да горурлануын аңлап була – каләмле тарихыбызга багышланган мондый җыентык ул җитәкчелек иткән чорда дөнья күрде бит!

– Әдәбият тарихыбызны ташка бастык, моны зур милләт кенә эшли ала, – диде ул, канәгатьләнеп белдереп.

Китапның авторы халык шагыйре Равил Фәйзуллин басмага өч гасыр әдипләренең кервәнә һәм үзенә аларның күбесе белән аралашып яшәү бәхете тиюенә туктады.

– Миңа бу китапны беркем дә кушып яздырмады. Намусым, вөҗданым гына: «Син моны эшләргә тиеш!» – дип, гел тәкрарлап торды. Күңелем, җаным кушканга яздым. Үзем аңлаганча, үзем белгәнчә яздым, – диде ул һәм бу эшнең шактый озакка, 20 елга сузылуын, архивларда утырырга туры килүен дә җиткерде.

«Бу китап – әдәбиятыбыз турындагы уйлануларымның бер сөземтәсе. Гомумән, язучы үз эшенең фидакаре икән, әдәбиятның үткәненә һәм киләчәгенә битараф кала алмый. Бүгенге рухи халәтебезгә аның үз фикере, үз мөнәсәбәте калыплаша. Һәрхәлдә, шулай булырга тиеш», – дип яза ул китапның кереш өлешендә.

Китапның мөхәррире Гүзәл Габдуллаҗанова, тарихчылар, әдәбият галимнәре Индус Таһиров, Тәлгат Галиуллин, Фоат Галимуллин, каләмдәшләре Разил Вәлиев, Зиннур Мансуров, Рәфкать Кәрами, Камил Кәримов китапның бик зур фәнни эш, кандидатлык диссертациясенә тиң булуын әйттеләр.

Туй үпкәсез булмый дигәндәй, кайбер язучылар китапка бүгенге заман әдипләренең барысының да кереп җитмәвен искәртте. «Алар турында язылыр әле, максатым үткәннәрне, киткәннәрне халык хәтерендә калдыру иде», – диде автор. Китапның икенче һәм өченче томнары да булыр дигән өметле сүзләр дә ишетелде кичәдә.

Йолдыз ШӘРАПОВА.

ПОЧТАДАН

Хыяллар чынга ашканда

Гомер буе хыялланып та, яшь чакта Ленинградны күрергә җай чыкмады. Әмма лаеклы ялга чыккач, Санкт-Петербургта хәтта ике тапкыр булырга туры килде. Бер җәйдә балалар белән тарихи шәһәрнең фонтаннарына, Петергоф паркына, Нева елгасындагы су трамвайларына сокланып кайткан идек. Петр Інең моннан 300 ел элек зур авырлыклар белән сазлыкта шундый шәһәр төзетә алганына гаҗәпләндек. Петербургны салуда татарлар катнашуына горурландык. Петр I, безнең милләт турында уңай бәя дә биреп: «Татарлар итек һәм тун кияләр, шуңа алар салкынга чыдый, өстәмә киендерәсе юк», – дип язып калдырган.

Күптән түгел кышкы Санкт-Петербургны да күреп кайттык. Андагы татарлар җәмгыяте Бөтендөнья татар конгрессының Казан булегенә ветераннарны, татарлар оешмалары вәкилләрен кунакка чакырып мөрәҗәгать иткән. Татар конгрессының Казан бүлеге рәисе Фәрит Мифтахов җитәкчелегендә Татарстаннан 38 кеше сәяхәткә бардык. Бик күп мәчет, музейлар күрдек. Истәлекле урыннарда булдык. Миләтләр йортында Санкт-Петербург татарлары белән очрашу узды. Анда безне Татарстанның Санкт-Петербург һәм Ленинград өлкәсендәге даими вәкиле Ренат Вәлиуллин мәчеттән дин әһелләре, күренекле татар шәхесләре белән таныштырды. Без исә Казан кунаклары – милләттәшләребезгә татарча җырлар бүләк иттек. Безнең белән Яшел Үзән районының Норлат балалар йортыннан килгән сәләтле сабыйлар гармунда да уйнап күрсәттеләр, шигырьләр сөйләделәр. Кыскасы, сәяхәт бик тә мәгънәле, файдалы, күңелле узды. Барлык ветераннар исеменнән, безгә чит шәһәрләр күрү мөмкинлеге биргәне өчен, Фәрит Мифтаховка һәм аның ярдәмчесе Рәмзия Галәметдиновага зур рәхмәтебезне җиткерәбез. Мондый сәяхәтләр дәвамлы булсын.

Әлфия ЗАКИРОВА,
Казан.

Рәхәтләнеп ял иттек

Авыл кешесе өчен бердәнбер күңел ачу урыны булып мәдәният йорты тора. Әле менә күрше Мәмсә авылында яңа төзекләндерелгән мәдәният йортында зур концерт булып узды. «Бер картлыкта, бер яшьлектә» дигән кичә дә авыл халкы күңеленә хуш килде. Үзебезнең Ташкичү авылы мәдәният йортында «Әбиемнең сандык серләре» дигән кичә шулай ук мәгънәле чара булып истә калды. Ул татар халкының онытыла барган изге бәйрәмнәрен, гореф-гадәтләрен, йола, бәет-мөнәҗәтләрен хәтердә яңартты. Серле сандыктагы тәрәзә пәрдәләрен, чигүле сөлгеләрне, калфак-түбәтәйләрне, өстәл япмаларын күреп, яшь буын да сокланды. Әйтерсең лә борынгы авыл өендә кунак булдык. Һәркем шигырь укыда, җырда үз осталыгын күрсәтә алды. Әби ролен башкарган Рузалия Насыйбуллина гореф-гадәтләребез хакында сөйләде. Бәйрәмне оештыруда Венера Мостафина, Гөлфия Мәгъсүмова, Тәнзилә Вәлиеваның өлеше зур булды.

Нурания ХӘСӘНОВА,
Арча районы.

Рольләрне алыштылар

Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры артистлары Казанның Авиатөзелеш районы, 10нчы гимназиясендә кунак булды. Татар театрына нигез салучыларның берсе – күренекле драматург, артист һәм режиссер Кәрим Тинчуринның тууына 130 ел тулуга багышланган әлеге очрашуда Татарстанның халык артисты Ләлә Миңнуллина, Татарстанның атказанган артисты Зөлфия Вәлиева, Гөлчәчәк Хафизова, музей мөдире Розалия Чабатова катнашты.

Балалар очрашуга җентекләп әзерләнгән: алар Кәрим Тинчуринның бай иҗади мирасын барлап, «Назлы кияү», «Американ», «Сүнгән йолдызлар», «Зәңгәр шәл» спектакльләреннән өзекләр күрсәтте. Аннары артистлар белән әңгәмә кордылар. Тинчуринлылар, үз чиратында, укучыларга театр сәнгатенә ничек килеп эләгүләре, Кәрим Тинчурин әсәрләре буенча сәхнәләштерелгән кайсы спектакльләрдә уйнаулары, артистларга кирәкле сыйфатлар турында сөйләделәр. Гөлчәчәк Хафизова бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның берничә шигырен укыды. Балалар артистларга үзләрен кызыксындырган сорауларын бирде.

Музей мөдире Розалия Чабатова 1933 елның 6 ноябрендә Питрәч районының Шәле авылында Кәрим Тинчурин һәм Кави Нәҗминең Гали Ильясов куйган «Булат бабай гаиләсе» дигән беренче премьера спектакле күрсәтелүен искәртеп, 10нчы гимназия музеена әлеге тарихи спектакль афишасының күчерелмәсен бүләк итте.

Ләйсән ИСХАКОВА,
театрның матбугат үзәге хезмәткәре.

«Давыл үзе безгә кагылмады – тик афәте төште иңнәргә...»

16 гыйнвар көнне 72 яшендә Татарстанның халык шагыйре, Габдулла Тукай бүләге иясе Лена Шагыйрьҗан белән хушлаштык. Башлыча лирик-публицистик шигърият тарафдары иде ул. Мәрхүмәнең кырыгы җиткән көннәрдә кабат аның шигырьләрен күңелдә яңартсак, ул, һичшиксез, шагыйрә рухына дога булып барыр.

ЛЕНА ШАГЫЙРЬҖАН

Туган телгә мәдхия

Әй син, телем, туган телем,
тамыр телем.
Җир астыннан тарих серен
табыр телем...
Әй син, телем, рәхәт телем,
авыр телем.
Телне тешләп канатырлык
сабыр телем...
Синең белән рәхмәт укыйм,
теләк телим.
Җырга салып сине, милли
көйләр көйлим.
Табындагы икмәгем күк
телем-телем,
Табынам сиңа,
синсез бер тәм
тоймас телем...
Әй син, телем, айлы төнем,
якты көнем.
Әремнәрдән әче,
балдан
татлы телем.
Сине саклап калыр өчен
күпме белем
кирәклеген аңладым мин,
белдем бүген...
Әткәм-әнкәм мирасы син
миңа күчкән.
Чишмә үзе сусаганда,
сине эчкән...
Алдым сине,
күчтең төбем-тамырыма,
күчтең күзәнәкләремә,
карыныма...
Кердең аңга, яттың җанга,
сеңдең канга.
Һәр гөл белә үз исемен
син кушканга...
Җиһандагы һәрбер җисем,
һәрбер матдә,
Исемем бар, дип, гүя сиңа
рәхмәт әйтә.
Әй син, телем, батыр телем,
горур телем.
Җирдә йолдыз булып балкып
торыр телем.
Халкым теле, хак телем син,
йөрәк телем.
Киләчәгем өчен мәңге
кирәк телем!

Кипсә яшел карасы...

Бирде дөнья кирәкне,
Еламаска өйрәтте...
Хәсән Туфан

...Еламаска өйрәтсә дә,
Җырламаска өйрәтә
алмады, шөкер, дөньясы...
Җыр исән-сау йөрәктә!
Инде канығып язмышка,
аны да алса тартып,
еламый да, җырламый да
яшәүдән үлем артык...
Еламаска өйрәтсә дә,
җырламаска өйрәтә
алмады шул дөнья-камчы...
Җәрәхәтле йөрәктә
янсын яра, бәйләмәгез,
саркып торсын, канасын!..
Шагыйрь маңып җырын язар,
кипсә яшел карасы...

Давылдан соң

Без давылга юлыкмыйча калдык...
давылдан соң күрдек дөньяны.
Актарылып сынган имәннәрен
куркып карап йөрдек без аның...

Югалышып катып калдык бер мәл,
таянырбыз диеп, кемнәргә...
Давыл үзе безгә кагылмады –
тик афәте төште иңнәргә...

Тормыш – диңгез инде...
Бармы соң ул
дулкыннарның берчак тынганы?..
Нишләтергә белми тордык бер мәл
давылдан соң калган дөньяны...

Иман әлифбасы

Алдан күреп алданулар...
Ышанычлар – җимерек, ватык.
Кояш төшкән җанибызга
Иман яңартырга вакыт!..

Телдән язып, деннән язып,
Яшәгәндә хәвефләнеп,
Изге бер сүз килә телгә,
Шәрехләп үз хәрефләрен...

Таркатсаң да, таралмаслык
Бербөтен ул, әйтсәң җыеп:
Төп кануны яшәешнең
Дүрт хәрефкә беткән сыеп:

Иман – Ирек ул иң элек,
Һәм – Мәхәббәт аннан килеп,
Иман – Акыл, Иман – Намус –
Иман әлифбасын белик!..

Калыр җирсез-иманасыз,
Имансызга чыкса бәндә.
Төзәлмәслек чирләр булып,
Җан бушлыгы кайткан тәнгә...

Яшим дисәң исән-аман,
Иманыңа табын, инан:
Айга карап пышылдыйм мин,
Берүк Ходай бирсен иман!..

Авызым тулсын иман белән,
Җаным тулсын иман белән.
Иман китерер вакыт җиткән
Һәммәбезгә берәм-берәм!!!

Ап-ак сөлге

Ак сөлгемә
керләр кунды,
таплар иңде,
кара сеңде...
Ап-ак иде сөлгем,
инде –
кара сөлге
кара сөлге...
Кара таплар актан көлде
хурлап көлде,
урлап көлде...
Кара таплар белми әле
ап-ак күбек белән җилне.
Җиде юдым, җиде удым,
ак күбеккә керен кудым..
Җиде чайкап җилгә элдем,
Җилфер-җилфер кибә сөлгем.
Ап-ак сөлгем
минем билгем.
Кояш белән кушылып көлдем...
Аклык кадерен,
сафлык кадерен
Керләр юа-юа белдем...

Мәхәббәт көянтәсе

Калды бит әле, калды бит
«Яратам» дип әйтәсе...
Салават күпере булып
Мәхәббәт көянтәсе
Иңнәрдә калды эленеп,
Кайда соң чиләкләре?
Сөюнең бер йотым судай
Бар икән кирәкләре...
Барасы калды чишмәгә
Талир тәңкәләр тагып.
Чыңнарына чишмә үзе
Кушылыр хәйран калып.
Барасы калды чишмәгә
Пар чиләкләрне тагып.
Безнең мәхәббәт чишмәсе
Бетмәгән әле агып...
Калды шул әле, калды шул
Яратам дип әйтәсе.
Иңнәремдә эленеп тора
Мәхәббәт көянтәсе...

Татар шагыйренең бәясе

Имеш, хәзер шигырь яратмыйлар,
Кирәк түгел шигырь, янәсе.
Шигырьнең дә, шагыйрьнең дә, имеш,
Арзанайган, төшкән бәясе.

Рухи инфляция – шигъриятнең
Гаебе түгел юкса, бәласе...
Җыр кадерен белгән затлар кайда?
Кемнәр куя шигырь бәясен?

Сүзнең тәмен белми картаючы
Шигырь дегустаторларына
Җавабым шул: төкермәгез әле
Галиҗәнаб шагыйрь җанына!!!

Кем ул «бетерәм дип, башыгызны»,
Киерел тарткан уклы җәясен?
Кол Галидән сора, күпме тора
Татар шагыйренең бәясе?!! –

Кыйммәт тора! Үзе хәтле тора!
Чын шагыйрьнең булмый арзаны.
Кабат бәя биргән Тукаена,
Еллар узгач, Печән базары...

Шул бәһане дөнья базарында
Төшермичә саклый Җәлилләр!
Мең кат көчле усал гайбәтеңнән
Утны-суны кичкән дәлилләр.

Лирик җырлар гына языйм, дисәм,
Булып чыга тагын сәясәи...
Саклап калса телен, мәңге төшмәс
Татар шагыйренең бәясе!!!

Милли, милли миллионнар

Милли, милли миллионнар
Чәчелгәннәр давыл-җилгә...
...Яз кайтмасак, көз кайтырбыз,
Бер кайтырбыз туган илгә...

Милли, милли миллионнар
Сибелгәннәр төбәк-төбәк...
Ни көтәләр, ни уйлыйлар
Туган якка күзне төбәп...

Тарта җаны, тарта каны,
Тартып тора милли моңнар...
Ник уянмый, йоклый һаман
Милли, милли миллионнар?

Тарих безнең авыр инде...
Белмим, кемгә ошасын ул!
Милләтеңә охшамыйча,
Тагын кемгә охшасын ул!..

Милли, милли миллионнар...
Милли кызлар, милли уллар...
Укмашырга, тоташырга
Җитми мәллә юкса куллар?..

Чакырып тора кайтыр юллар,
Көтмәсә дә такыр юллар...
Оча тора, китә тора
Милли, милли миллионнар...

Милли байлык – милли саулык.
Милли җимерек, милли ватык...
Җилләр уңай искән чакта,
Җилгә ябышып кайтыр вакыт...

Яз кайтмасак, көз кайтырбыз...
Үтә гомер, көтми еллар.
Өзелеп бетсә милли кыллар,
Кемнәр көләр, кемнәр елар?..

Җыен ясап, кыен ашап,
Керәшкәндә йөзләр, уннар,
Ник кушылмый туган телгә
Милли, милли миллионнар?..

Ага Идел, ага болыт,
«Исә җилләр, кучә комлар...»[1]
Кыйблабыз бер, берләшик лә,
Милли, милли миллионнар!!!

[1]*Дәрдемәнд шигыреннән.*

Шаһит язмалары

Күпләргә данлыклы «Бәкер» шифаханәсе аша таныш Бәкер авылы бар. XVIII гасыр уртасында Әбүбәкер Солтанов дигән кеше нигезләгән авыл. Бәкер картның нәселе бик зур һәм бүген дә ярты авыл аның дәвамчылары дияргә була.

ТАРИХ

Илфак ШИҺАПОВ

Авылның кульязма тарихы барлыгы турында картлар әйткәли иде, тик күпме эзләп тә, аның эзенә озак еллар төшә алмадым. Күпләр фикеренчә, әлеге тарих 60нчы елларда укмы, 1976 елда Иске Иштирәк мәктәбе янгандамы юкка чыккан дип саналып килде. Ләкин бер классикның «кульязмалар янмый» дигән гыйбарәсе дөрес булып чыкты. Иске Иштирәк авылы тарихы буенча материаллар туплап йөргәндә, миңа шул авылның мәктәп директоры, Бәкер авылы кешесе Әсгать Малик улы кульязма һәм аның шактый тулы булган тәрҗемәсе язылган дәфтәр тапшырды. Дәфтәрдәге искәрмәләргә караганда, ул заманында Сибгать Насыйбуллин кулында булган. Сибгать аны тәрҗемә дә итеп караган, аннан дәфтәр Керкәле авылы кешесе Җәүдәт ага Һилаловка эләккән һәм ул 1991 елны кульязманы шул чактагы мәктәп директоры Талия Бәдретдиновага тапшырган. Кульязманың төп нөсхәсе түгел бу, ә 1983 елда Хәниф мулла улы Фуат ага Вилданов күчереп язган нөсхә. Әлбәттә, 1928 елда Кәшшәфетдин мулла Бакиров хәтердән язган тарихта кайбер төгәлсезлекләр бар. Шул ук вакытта кульязма тарих безгә бернинди архивлардан алып булмаган мәгълүматны бирә.

Гарәп хәрефләре белән язылган кульязманы Айдар Гайнетдинов кириллицага күчерде. Кульязманы җентекләп өйрәнсәң, тарихны язучы Кәшшәфетдин мулла шәхесе бик кызыклы яктан ачыла. XIX гасыр азагы татар интеллигенты – Кәшшәф мулла турында шулай диярге була: тормыштагы бар нәрсә белән кызыксынып, һәр нәрсәгә үз карашы булган, патша сәясәте белән дә кызыксынган, ул чорда чыккан «Тәрҗеман» газетасын да яздырып алган бер кеше булган ул. Үзе Чыршылы мәдрәсәсендә Ризаэддин Фәхреддиновта укыган. Соң язмышы – аяныч, репрессиягә эләгеп сөргенгә озатыла. Йортына хезмәтчеләре хуҗа була. Сүз уңаеннан, Бәкердә, Кәшшәф мулланың нигезе, ул салдырган таш келәтләр бүген дә тора әле... Тарих шактый зур, шуңа күрә, бүгенге язмада аның кайбер өзекләренә генә тукталасы иттем. Әйтик, Кәшшәфетдин үзе шаһит булган 1921 елгы ачлык галәмәтләренә, мәчетләр салыну тарихына, кайбер муллалар турындагы кызыклы мәгълүматка. Бүген тарих белән кызыксынучылар байтак. Бәлки әлеге язма кемнәргәдер кызыклы тоелыр. Тере истәлек ич бу. Шул ук Фатыйх Туйкин турында, мәсәлән. Хәер, башкалары да...

* * *

«...Мөхәммәдфатих Мөхәммәдзакир улы Туйкин турында. Зәй Каратайдан килде. Ул укытучы булып эшләде. 1920 елның 13-14 февралендә ерткычларча үтерелә. Бу кеше шушы елда совет хөкүмәте тарафыннан безнең авылга рәсми укытучы булып килгән иде. Гаять гүзәл холыклы, гыйлеме дә аз түгел иде. Мәхкәмәи шаргыйдән имам хатыйп мәдрәсәсеннән алган шәһадәтнамәсе дә бар иде. Әткәсе Мөхәммәдзакир мөәзин иде. Ошбу Фатих 1920 елны 13-14 февраль көнне совет хөкүмәтенә каршы чыккан сәнәкче яки чапанчылар тарафыннан ошбу Бәкер авылында бик җәфаланып атып үтерелде һәм тиреслеккә илтеп ташланды. Сәнәкче отряд дигәннәре кемнең котсызы беләндер Каратай, Чүти, Куакбаш авылларыннан җыелган шарлатан вә хулиганнар иде. Үзебез дә ошбу отряд фетнәсеннән көч-хәл белән генә калдык. Укытучы Факихә кызыбыз да көчкә котылып калды. Фатих мәрхүм тиреслеккә ташлангач кич караңгы булганчы шунда ятып караңгыда йортка кайтарып куелды. Икенче көнне аны күмәргә никадәр халык тәшдик ителсә дә, куркулары, фетнәләнүләреннән куркып күмүче булмады. Нихаять ошбу көнне ясигътан соң үземнән башка 2 кеше белән хөрмәтләп җеназа укып күмдек. Кабере Бәкер каберлегенең җәнүб шәрык (көньяк-көнчыгыш. – **И.Ш.**) тарафындарак урталыктадыр. Өстендә рәшәткә-ихатасы да бар.»

«...1897 елда ошбу Россия мәмләкәтендә перепись вакыйгасы булды. Бу перепись халыкның хисабын алу өчен генә булса да, хөкүмәтнең ул вакытта чит дин әһелләренә шик тудыру мөмкин дип, бөтенләй христиан диненә кертү сәясәте кулланганы өчен мөселманнар моңа нык каршы тордылар. Бу һәркайда ризасызлык тудырды.

Хөкүмәттә алда ук: «дингә тиелми, фәкать халыкның хисабы гына алыначак, курыкмагыз», дигән мәгънәдә күп язулар таратылды. Ләкин халык риза булмады. Шул сәбәптән, губернатор үзе гаскәр белән чыгып, ошбу тирәләрдә йөреп карышучыларны 50-100-150 шәр чыбык суктырды, күп кешеләр төрмәгә ябылды. Төрмәгә ябылучылар эчендә муллалар да бар иде. Соңрак хөкүмәт халыкның карышуга диненнән куркү сәбәпле икәнлеген белгәч, бөтенесе гафу ителде.»

«...Совет хөкүмәте дини укытуларны тыеп РСФСР халык комиссариатлары советның 1918 елның гыйнварындагы декреты түбәндәге гомуми кагыйдәләрне урнаштырды. Динне бары 18 яшьтән ким булмаган зур кешеләргә генә укытырга рөхсәт итәргә мөмкин, диелгән. Ошбу яңа законга бинаән 1922-23 елларда булыр, без муллаларны Бөгелмәдән килгән бер мәшһүр комиссар Керкәле авылына җыеп дин укытудан катгый рәвештә тыю турында имза алды. Шуннан соң без дә дин укытудан тыелдык. Безне бу җыелышка чакырып повестка җибәрүче Спиридон волосте председателе Фәррахетдин Гыймаев иде. Мәктәпләр икесе дә хөкүмәт кулына керде.»

«...Иң олы вакыйгаларның берсе – ачлык вакыйгаларыдыр. 1914 елда сугыш башлангач халыкта дәүләт кими, чәчүләр азая башлый, булган азык та төрле юллар белән кимүгә йөз тота. 1921-1922 еллар килеп җитә. Бу елларда хакыйкый фаҗигаләрдән ачлык башлана. Алабута оны да бетә. Төрле агач бөреләре, тамырлар калмый ашала. Боларның табигый азыклары юк дәрәҗәсендә, шул сәбәпле халык шешенә башлый. Хөкүмәт бу вакытта чаралар күрсә дә, ачлык гомуми булгач, җитештерә алмый. Юлда да үлек, авылда да үлек. Юлда үлгәннәрдән берәр атна күмелмичә ятулар булды. Чөнки кабер казырга кеше табып булмый. Бер кабергә 2-3-4 үлекне дә куялар иде. Шулай булса да, бу Бәкер авылы бөтен тирә-якка караганда туграк булды. Бездә печән һәм башка дәүләтләр баррак иде. Тирә-як авылларда үлекләрне каравыл йортына җыеп берәр атна тоталар иде. Көненә 20-30 ар үлек булып зур базларга күп итеп күмәләр иде. Бу елларда кеше ашау фаҗигаләре дә күп булды. Әби авылында (Сарабиккол. Лениногорск районындагы авыл. – **И.Ш.**) каравыл йортындагы үлекләр югала торган булган. Тәфтиш вакыйгасында бер йорт җәмәгате шушы үлекләрне ашап торганнары беленгән. Юлтимер авылының 3 нче мәхәлләсендә бер хатын, улы белән бер класста укый торган кызны чакырып кайтара да, әлеге хатын кызны җеп белән буа. Улы балта белән сугып, үтерәләр. Шундук кисеп алып пешереп ашыйлар. Икенче көннәрдә хатын үзе дә, улы да үлем хәленә килә. Шул вакытта әлеге малай үз туганын үтереп ташлаганнарын, шуны ашау сәбәбеннән анасының үлгәнен үз теле белән икрар итә (сөйли. – **И.Ш.**). Малай да озак тормый үлә һәм шуннан соң үтерелгән кыз баланың калган гәүдә үлешләрен җыйнап алып, өчесе бер көнне күмелгәннәр. Бу вакыйганы шул мәхәлләнең үз имамы сөйләде.

Моннан башка да үз балаларын ашау вакыйгасы күп булганлыктан сүзне озайтмыйбыз, күпкә китәдер.

Моннан башка ризык эзләп саиллек итеп торучыларның кунарга кергән җирләреннән югалулары, үтерелүләре төрле урыннарда күп булган. Ачлык елны юлда төрле урыннарда үлеп яткан билгесез кешеләрне, хәер сорашучылар күп сөйләделәр. Үзебездә 1922 ел җәйгә чыккач баканы да күп ашадылар. Ачлык фаҗигасын сөйләп кенә бетерерлек түгелдер. Аллам кәрим бу авыр көннәрне исәннәргә моннан соң бирмәсен иде!»

...Кәшшәфетдин Бакиров язган тарих бер сулышта укыла. Юк, үземнең туган ягыма кагылышлы булганлыгы белән түгел, уйланып, анализлап, фактларга нигезләнеп язылганнан да, Кәшшәф мулла үзе шаһит булган нәрсәләр турында язылудан да. Бирсен Ходай, киләчәктә аның «Бәкер тарихы»н китап итеп тә бастырасы булыр, чөнки ул язган әйберләр – татар тарихының бер тарихи сәхифәсе ул.

Җәяүленең җаны – «аягында»

ХӘРӘКӘТ ИМИНЛЕГЕ

Транспорт чараларын идарә итүчеләрнең узган ел Казанда җәяүлеләрне бәрдерүнең 874 очрагы теркәлгән, шул сәбәпле 30 кешенең гомере өзелгән, 866 кеше төрле авырлыкта имгәнү алган. Казан шәһәре буенча эчке эшләр идарәсенең ЮХИДИ бүлеге пропаганда хезмәте мәгълүматларына караганда, башкалада быелның беренче аенда җәяүлеләрне бәрдерүнең 50 очрагы – бер кешенең үлеменә, 50 кешенең имгәнүенә китергән.

– Юл хәрәкәтендә – җәяүле өстен. Транспорт чараларын идарә итүчеләр шул кагыйдәне аңнарына сеңдерсеннәр иде, – ди Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгының ЮХИДИ идарәсе җитәкчесе Ленар Габдерахманов.

Казанда узган ел транспорт чараларын идарә итүчеләрнең җәяүлеләрне бәрдергән 361 очрагы нәкъ җәяүлеләр юл кичүләренә туры килә: сигез кеше үлгән, 361есе имгәнгән. Быелның гыйнвар аенда башкалада җәяүлеләр юл кичүендә, машинага бәрелеп, 27 кеше имгәнгән, шөкер, үлүчеләр юк.

– Юллардагы аварияләрнең күбесе тизлек чикләрен сакламаудан килеп чыга, – дип кисәтә республиканың баш автоинспекторы Ленар Габдерахманов.

Махсус тамгалар куелган кичүдә җәяүлегә юл бирмәсәң, 1500 сум штраф салына. Россия Эчке эшләр министрлыгы әлеге штрафны 2500 сумга җиткерү тәкъдиме кертте. Хәзер бу тәкъдим Россия Дәүләт Думасында карала.

Руль артына утырыга, Россия Федерациясе Административ хокук бозулар кодексының 12.24 нче маддәсен искә төшерү зыян булмас. Транспорт чарасында җәяүлене җиңелчә бәрдерсәң, 2500 сумнан 5000 сумга кадәр штраф яки транспорт чарасын идарә итү хокукы таныклыгыннан бер елдан ел ярымга кадәр мәхрүм каласың. Җәяүлене бәрдереп, сәламәтлегенә уртача авырлыкта зыян салсаң, 10 мең сумнан 20 мең сумга кадәр штраф каралган, транспорт чарасын идарә итү хокукы 1,5 елдан ике елга кадәр чикләнә. Җәяүлене бәрдереп, сәламәтлегенә нык зыян китерсәң, транспорт чарасын идарә итү хокукы өч елга чикләнә, шуның өстенә өч елга иректән дә мәхрүм буласың. Җәяүлене бәрдереп үтерсәң, дүрт ел мәҗбүри хезмәт һәм җиде елга кадәр төрмә көтә. Транспорт чарасын идарә итү хокукы таныклыгы алына.

Дамир БӘДРИЕВ.

ОЙЛ-СЕРВИС
общество с ограниченной ответственностью
OIL-SERVICE Ltd.
КАПИТАЛЬНЫЙ РЕМОНТ СКВАЖИН
В связи с увеличением производства работ на территориях Республики Башкортостан и Оренбургской области для работы вахтовым методом 15х15 и создания кадрового резерва приглашаются следующие специалисты:
- Мастер по ремонту скважин (КРС, ПРС);
- Машинист подъёмника АПРС, УПА, А-50;
- Машинист КМУ;
- Моторист ЦА-320;
- Водители категории BCDE, ДОПОГ.
Требования: опыт работ не менее 3-х лет, наличие документов подтверждающих квалификацию.
Собеседование проводиться по адресам:
Респ. Башкортостан, г. Октябрьский, ул. Кызыл Маяк 76/4;
Тел.: 8 (34767) 5-52-40; +7 (937) 30-44-130; +7 (927) 94-10-330;
с. Краснохолмский, ул. Парковая 9; +7 (927) 302-93-71;
г. Бугуруслан, ул. Пилюгинское шоссе 3; +7 (922) 84-51-946;
эл.почта для анкет: hr@oil-service.pro; или 9410330@mail.ru; подробности на сайте: http://oil-service.pro
Реклама

Японский бренд - Datsun on-DO
Цена по прайсу – от 436 000 рублей:
– 70 000 скидка по утилизации
– 30 000 субсидия от банка при оформлении кредитного договора на 2-3 года
= от 336 000 р.*
datsun-akoc.ru

* Предложение ограничено и действует с 1.02. до 28.02.2017. Цена действительна на а/м Datsun on-DO в базовой комплектации 2016 г.в. с учетом всех действующих акций, проходящих в салоне. Условия и тарифы могут быть изменены в одностороннем порядке. Кредит предоставляется АО РН БАНК. Предложение не является офертой и носит информационный характер. Изображение а/м может отличаться от представленного.
**Подробности в салоне продаж. Реклама
Казань, пр-т Победы, 212
(843) 510-30-30
АКОС
Зимняя резина + полный бак бензина в ПОДАРОК!*

КАЗАНСКИЙ ЗАВОД СИЛИКАТНЫХ СТЕНОВЫХ МАТЕРИАЛОВ
КИРПИЧ от 8,24 р./шт.
5-707-909
5-719-259
www.kzssm.ru
ГАЗОБЕТОН от 50,40 р./шт.
ЖБИ изделия
ОТГРУЗКА КРУГЛОСУТОЧНО
Реклама

Нияз Бишбалта төзеде.

Чайнворд

«Җиңү өчен утка кердек без»

1. … кердең,
Курку белмәдең.
Ватан йөзенә
Тап төшермәдең.

2. … чаба батыр, … бара,
Чаң тузаны кала артында.

3. Үлгәндә дә йөрәк тугры калыр
Шигыремдәге изге … .

4. Катюшалар командиры,
Серле туплар … ,
Яу кырында дошманнарны
Ялкыны белән кыра.

5. Мин исән,
Мин үлмәм
Бетмәс көч …
Туган илемнән.

6. Икебезгә тиде берьюлы
Бер минаның ике ярчыгы.
Берсе калды сержант Фоминда,
Икенчесе – … тәнемдә.

7. Кичер, әнкәй, кичер
Чит ил туфрагында
…
Ятып калганымны.

8. Исәнме икән минем иркәм,
Үлдеме икән, ранен микән,
… пленда микән?

9. Картаймагыз … , ветераннар,
Европаны саклап калган ирләр.

10. Мин … яшем тулган көнне
Үлеп калдым сугыш кырында.

11. Батыр … китте акбүз атта
Туздырырга дошман сафларын.

12. Илгә җиңү яулап,
… кебек шаулап
Кайткан батырларның даны зур.

13. Намусы бар егет … ятсын,
Ил читенә бүген яу килгән.

14. Унтугыз ел … ул яра,
Өченче көн тоташ кар ява.

15. Дошман явын тар-мар … чакта,
Йөрәгеңнән кайнар кан тамды.

16. Үс, улым, син, күз … син,
Тынычлык сакчысы бул.

17. Һәм ир даны кайтты югалмыйча,
… ут булып янарга.

18. Үлем килде җир шарының
… баткан ягыннан.
Ватан өчен утка кердек
Сабантуй мәйданыннан.

19. Туплар … , җирләр тетри,
Йолдыз якты, төн кара.

20. Аналар … шикелле
Ут яна, уйлана, талпына.
Аналар хәтере шикелле
Җил йөри курганнар артында.

21. Даның яңгырый синең … –
Тын океанда, биек Карпатта.

22. Минем дустым … ,
Ул җиңеп өйгә кайтыр.

Җаваплар.
1.Утларга **2.**Алга **3.**Антына **4.**Аттыра **5.**Алам **6.**Минем **7.**Мәңгелеккә **8.**Әллә **9.**Әле **10.**Егерме **11.**Егет **12.**Ташкын **13.**Нигә **14.**Әрни **15.**Иткән **16.**Нурым **17.**Мәңгелек **18.**Кояш **19.**Шартлый **20.**Йөрәге **21.**Еракта **22.**Армиядә.

АФИША
1 – 6 МАРТ

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ
(ТАТАРСТАН УРАМЫ, 1)

Әлмәт Татар дәүләт драма театры гастрольләре

20 февраль «Бистә фәрештәсе» (Б.Брехт)
Башлана: 15.00
Билет бәясе: 250-300 сум

20 февраль «Кар астында кайнар чишмә» (А.Гыйләҗев)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 250-500 сум

21 февраль «Син кайда идең?» (Я.Пулинович)
Башлана: 12.00
Билет бәясе: 250-300 сум

21 февраль «Концерт-тамаша»
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 350-600 сум

22 февраль «Шүрәле-шоу» (Э.Шахов)
Башлана: 11.00
Билет бәясе: 150-200 сум

22 февраль «Шүрәле-шоу» (Э.Шахов)
Башлана: 14.00
Билет бәясе: 150-200 сум

22 февраль «Кибет» (Ж.Олжас)
Башлана: 18.00
Билет бәясе: 250-300 сум

22 февраль «Бабайлар чуагы» (И.Зәйниев)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 200-1200 сум

23 февраль «Зәңгәр шәл» (К.Тинчурин)
Башлана: 18.00
Билет бәясе: 200-1200 сум

24 февраль «Искән җилләр көенә» (З.Хәким)
Башлана: 12.00
Билет бәясе: 150-1000 сум

24 февраль «Диләфрүз – Remake» (Т.Миңнуллин)
Башлана: 18.00
Билет бәясе: 200-1200 сум

24 февраль «Агыла да болыт агыла...» (Х.Туфан, Т.Миңнуллин)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 300-350 сум

25 февраль «Хафалы бикәләр» (С.Юзеев)
Башлана: 12.00
Билет бәясе: 300-350 сум

25 февраль «Банкрот» (Г.Камал)
Башлана: 18.00
Билет бәясе: 150-1000 сум

26 февраль «Хуҗа Насретдин» (Н.Исәнбәт, С.Ваннус)
Башлана: 18.00
Билет бәясе: 200-1200 сум

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ
(ГОРЬКИЙ УРАМЫ, 13)

21 февраль «Мәхәббәт чишмәсе» (И.Мәхмүтова)
Башлана: 18.30

22 февраль «Ак тәүбә, кара тәүбә. Безнең көннәр» (Т.Миңнуллин)
Башлана: 18.30

23 февраль «Ефәк баулы былбыл кош» (А.Гыйләҗев)
Башлана: 17.00

24 февраль «Эх, алмагачлары!» (Ш.Фәрхетдинов)
Башлана: 17.00

25 февраль «Алтын көз» (Ш.Фәрхетдинов, Р.Заһидуллин)
Башлана: 17.00

26 февраль «Күрәсем килгән иде...» (И.Мәхмүтова)
Башлана: 17.00
Билет бәясе: 250-600 сум

«ӘКИЯТ» КУРЧАК ТЕАТРЫ
(ПЕТЕРБУРГ УРАМЫ, 57)

23 февраль «Волшебник изумрудного города» (А.Волков)
Башлана: 11.00, 13.00

25 февраль «Кошкин дом» (С.Маршак)
Башлана: 13.00, 15.00

26 февраль «Не хочу, не буду» (С.Маршак)
Башлана: 10.00

26 февраль «Айболит» (К.Чуковский, Н.Егорова инсц.)
Башлана: 11.00, 13.00
Билет бәясе: 200-300 сум

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ КАЗАН ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ
(ПЕТЕРБУРГ УРАМЫ, 57)

21 февраль «Алмачуар» (Г.Ибраһимов, Ф.Галиев инсц.)
Башлана: 14.00

22 февраль «Нигез ташлары» (Т. Миңнуллин)
Башлана: 18.30
Билет бәясе: 150-200 сум

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ
(ПАВЛЮХИН УРАМЫ, 73)

21 февраль Эльмира Сөләйманова концерты
Башлана: 18.30
Билет бәясе: 400-1000 сум

23 февраль Чулпан Йосыпова концерты
Башлана: 17.00
Билет бәясе: 400-1000 сум

24 февраль Мурат Гайсин концерты
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 600-800 сум

26 февраль Илсаф концерты
Башлана: 18.00
Билет бәясе: 300-1500 сум

УНИКС
(ПРОФЕССОР НУЖИН УРАМЫ 2/27)

20-26 февраль «Мунча ташы»
Башлана: 18.30
Билет бәясе: 500-1200 сум

«ШӘҺРИ КАЗАН» РЕДАКЦИЯСЕНЕҢ КҮРГӘЗМӘЛӘР ЗАЛЫ
(ЧИСТАЙ УРАМЫ, 5)

«Күчеп йөрүче ХӘБӘР» – Халыкара сәнгать проекты күргәзмәсе. Проект авторлары Әлфия Ильясова (Татарстан) һәм Наталья Николаева (Саха-Якутия).
Керү ирекле (эш көннәрендә)

Фернат Насыйбуллин:
«Дәрәҗәлерәк рольләр уйныйсым килде»

Моннан 19 ел элек Тинчурин театрына мәдәният һәм сәнгать институтыннан бер төркем яшь артистлар килде. Хәзерге вакытта аларның сәхнәдә үз йөзе, үз урыны бар. Бүгенге көндә Кариев исемендәге Казан Татар дәүләт Яшь тамашачы театрында эшләүче Фернат Насыйбуллин шуларның берсе.

– Фернат, син көтмәгәндә генә Тинчурин театрыннан китеп бардың. Ни өчен кирәкле булдың?

– 13 ел буе Наил Шәйхетдинов, Исламия һәм Хәлил Мәхмүтовлар белән уйнау минем өчен зур мәртәбә иде. Әмма анда күбрәк эпизод рольләрдә генә уйнарга туры килде. Рухи азык җитмәде дисәм, дөрес булыр. Сәнгать белгече Станиславскийның «артист өчен кечкенә рольләр юк...» дигән сүзләре белән килешмим. Минем саллырак, дәрәҗәлерәк рольләр уйныйсым килде. Шуңа күрә театрда беркем белән дә араны бозмыйча китеп бардым.

– Яшь тамашачылар театрында ничегрәк кабул иттеләр үзеңне? Режиссер нинди рольләр белән сөендерде?

– Бу театрда иҗатымның икенче этабы башланды. Нуриәхмәт Сафин, Рәмзия Закирҗанова, Халидә Сөнгатуллина кебек киңәшләшердәй артистлар бар. Тәҗрибә туплау артистка бик ярдәм итә ул. Мәрхүм Наил абый Шәйхетдинов: «Артистка күпме роль булса да җитми», – ди торган иде. Чыннан да шулай. Мин биредә дүрт ел эчендә шактый рольләр уйнарга өлгердем. Разил Вәлиевнең «Әйдә барыйк, кызлар карыйк» спектаклендә – Хәмит, Рабит Батулланың «Кичер мине, әнкәй» әсәрендә – Әбүбәкер, Рәдиф Сагъдинең «Гашыйклар утравы»нда – Генерал, «Башмагым», «Нигез ташлары»нда берничә рольдә һ.б. спектакльләрдә уйнау насыйп булды.

– Артист һәр ролен йөрәге аша кичереп уйнаса да, күңеленә иң якыны булмый калмыйдыр.

– Әйе, йөрәгемә сары май булып ята торган андый ролем минем дә бар. Ул – «Кичер мине, әнкәй!»дәге Әбүбәкер образы. Икенче пландагы гына роль булса да, яратып уйныйм. Әбүбәкер – хезмәт сөючән, өйләнмәгән, гомер буе яшьлек мәхәббәтен көтеп яшәүче ир-егет. Тамашачы да аны ярата. Узган ел аның өчен театрда «Тамашачы мәхәббәте» төрендә бүләк тә тапшырдылар. Хезмәтеңне күрә белсәләр, тагын да илһамланып эшлисе килә.

– Фернат, син театр белән генә чикләнмисең. Шактый еллар дәвамында сәхнә серләрен балаларны да өйрәтәсең. Театр түгәрәгенә килүчеләрне ничек сайлап аласың?

– Башта кастинг үткәрәм. Биетеп, җырлатып, шигырь сөйләтеп карыйм. Укытучылар да сайлап алырга ярдәм итә. Театр түгәрәгенә йөргән кызлар арасында сәнгать юлыннан китүчеләр дә бар. 3-4нче сыйныфларда түгәрәккә килгән укучылар белән «Беренче мәхәббәт» не уйнар дәрәҗәгә җиттек. Әле шушы арада гына премьераны мәктәптә укытучылар, ата-аналар бик яратып карадылар. «Көлдердегез дә, елаттыгыз да. Рәхмәт сезгә!» – дигән сүзләрне ишетү бик күңелле булды. Без әлеге спектакль белән «Иделкәем» театр фестивалендә дә катнашырга уйлыйбыз. Моннан берничә ел элек «Иптәш командир» дигән спектакль белән гран-при алган идек инде.

– Тормышта үз алдыңа куйган максатларың тормышка ашамы?

– Бу сорауны күптән көткән идем. Йолдызнамә буенча Кысла мин. Кысла бер адым артка чигенсә, ике адым алга китәргә тиеш. Мин йолдызнамәләргә ышанам. Чыннан да, үзәмә охшаш яклары күп икән. Ал лага шөкер, әлегә кадәр максатларыма ирешеп барам.

– Рольләр ятлап образларга кергәнче, артист йокысыз төннәрен дә шактый кичерә. Шулай да сәхнәдә синең өчен иң рәхәт мизгелләр нинди?

– Әгәр образга кереп бетәсең икән, шул чагында үзеңдә ышаныч тоясың. Синең 100 процент ышанып уйнаганыңны тамашачы яхшы кабул итә икән, иң җиңел, рәхәт мизгелләр әнә шул була.

– Гаиләдәгеләрнең синең һөнәргә мөнәсәбәтләре?

– Хатыным Гүзәлия бухгалтер булып эшли. Ул да, балалар да театрны яраталар. Мине аңлыйлар.

– Балаларыгыз нәрсә белән мавыга?

– Улым Булат үзе язган шигырен укып, төбәкара конкурста лауреат исемен алды. Кызыбыз Алия биюгә, музыкага йөри. Скрипкада уйный. Кичләрен өйдә концерт куярга ярата. Безне шулай ял иттерә.

Люция ХӘБИБУЛЛИНА.

Шәһри КАЗАН
ИНДЕКСЛАР
П2395 (3 тапкыр чыга)
П2430 (пәнҗешәмбе саны)
П2419 (оешмалар өчен)
www.shahrikazan.com

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ (НӘШЕР ИТҮЧЕ) – «ТАТМЕДИА» АҖ
«ТАТМЕДИА» АҖ ФИЛИАЛЫ ҖИТӘКЧЕСЕ – БАШ МӨХӘРРИР ГӨЛНАРА ИЛЬЯС кызы САБИРОВА.
ЧЫГАРЫЛЫШ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ – РАСИХА ГАБДЕЛБӘР кызы ИСМӘГЫЙЛОВА.
© Газетада басылган язмаларны файдалану, шулай ук өзекләр китерү өчен, «ШК» редакциясеннән язмача рөхсәт алу мәҗбүри. Редакциянең фикере авторларның фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин. Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк. Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Реклама һәм игъланнардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен аны бирүчеләр үзләре җаваплы.
РЕКЛАМА ХЕЗМӘТЕ
Тел: (843) 562-50-12,

ХАТЛАР БҮЛЕГЕ
Тел: (843). 562-50-03,
E-mail: shahri-kazan@tatmedia.com

НӘШРИЯТ
«Татмедиа» АҖ
420097, Казан, Академия ур., 2

16+
Сатудагы бәясе ирекле

Бу санның тиражы – 1545. Гомуми тираж – 5719.
Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
Заказ 678. Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәттә (Роскомнадзор). 2012 елның 27 августында ПИ №ФС77-50970 нче теркәлү таныклыгы алды. Газета атнага 3 тапкыр – сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә чыга. График буенча бу санга 17 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 17 сәгатьтә.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ
420066, Казан,
Чистай ур., 5 нче йорт
Тел.: (843). 562-50-12,
факс: (843). 562-50-07

БАСМАХАНӘ
420066, Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы